АФЗАЛ ШАМОВ

СОРЫ МӘЧЕ

АФЗАЛ ШАМОВ

СОРЫ МӘЧЕ

ХИКӘЯ

КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1990

ББК 84/2Р-Тат/-4
Ш19

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Художнигы И. ГАЛЛӘМОВ

Шамов А., Ш.

Ш 19 Соры мәче: Хикәя.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.; 72 бит.
ISBN 5 — 298 — 00484 — 9

Ш $\frac{4803010200-044}{М132(03)-90}$ 179—90

ИЗДАНИЕ ДЛЯ ДЕТЕЙ И ЮНОШЕСТВА

Шамов Афзал Шигабутдинович

СЕРЫЙ КОТ

Рассказ

(на татарском языке)

ИБ № 5705

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтов.* Художество редакторы *Ф. Хәсьянова.* Техник редакторы *Р. Шәфигуллина.* Корректоры *Ф. Гыйниятуллина.* Җыярга тапшырылды 31.08.89. Басарга кул куелды 8.05.90. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,5. Шартлы буяу-оттиск 10,0. Нәшер-хисап табагы 3,35. Тиражы 30 000 экз. Заказ Б-387. Бәясе 15 тиен.
Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19. КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

ISBN 5 — 298 — 00484 — 9

© Татарстан китап нәшрияты, 1986
© Афзал Шамов, 1990, өстәмәләр
© И. Галләмов, рәсемнәр, 1990

I

Буранлы февраль урталары иде. Дивизия каты, авыр һөҗүм сугышларыннан соң дошман частьларын тар-мар итеп, берничә авылны, район үзәге дип аталган бер шәһәрчекне азат иткәч, ике урман арасындагы ачыклыкта оборонага урнашты. Частьлар, подразделениеләр җиргә тирәнрәк казып урнашырга, ныгырга приказ алдылар. Дивизия сирәк атышлар, дошманны өзлексез кыпшап, тынычсызлап торудан гыйбарәт булган вак сугышлар алып бару белән бергә, авыр физик эшкә, оборонасын ныгытырга керешт е.

Өлкән сержант Әхтәм Сафин отделениесе, полк белән берлектә, икенче сафтагы окопларда калды. Аңа яңа гына азат ителгән авылның көнбатыш читен биләп, шунда ныгып урнашырга дигән приказ бирелде.

Бу авыл хәрби карталарда һәм югары командованиегә бирелгән донесениеләрдә Дятлевка дип йөртелсә дә, аның авыллыгы калмаган иде инде. Фашистлар аны җир белән тигезләгәннәр, йортларын, каралтыларын

яндырганнар, бөтен авылда бердәнбер таш бина булган мәктәпне, астына мина куеп, шартлатканнар, урамнардагы, бакчалардагы агачларны кискәннәр, корытканнар, терлекләрне һәм урманга, партизаннар янына качып китәргә өлгермәгән эшкә яраклы кешеләрне Германиягә куып алып киткәннәр, карт-карчыкларны, балаларны атып үтергәннәр. Авылда хәзер бер җан иясе юк, хәтта каңгырып йөрүче этләр дә, мәчеләр дә күренми, алар йә качканнар, йә кырылып беткәннәр.

Сугышчылар, оборонага урнашкач, көн-төн окоп казыдылар, дошман артиллериясе атып, тынычсызлап торуга карамастан, аны тирәнәйттеләр, ныгыттылар, тик шуннан соң гына землянкаларга тотындылар.

Сафин үз отделениесенә землянка урыны итеп бер өйнең идән астын сайлады. Уңай урында, траншея буенда гына. Әгәр казып, ныгытсалар, отделениегә бик җитәчәк, хәтта иркен дә булачак. Чөнки отделениедәге сугышчылар кимегән, бары җидәү генә калган иде.

Беркөнне караңгы төшкәч, отделениенең постта булмаган сугышчылары эшкә керештеләр, төн буе идән астын чүп-чардан арчыдылар, казыдылар, тирәнәйттеләр, өстенә өч кат бүрәнә җәеп, калын итеп балчык өйделәр, дошманга күренмәсен өчен, түбәсен кар белән капладылар. Төнлә берничә тапкыр тревога булып, аларга, көрәкләрен, кәйләләрен ташлап, кулларына коралларын алырга, окопка йөгереп чыгып, үз урыннарына барып басарга туры килсә дә, таң сызылганчы землянканы тәмамладылар, ишеккә плащ-палатка корасы гына калды.

Әхтәм Сафин инде плащ-палатканы кора да башлаган иде. Ул арада ефрейтор Әнәс Сибгатуллин, таза, озын буйлы, каты кара чәчле, шундый ук кара кашлы, өй җанлы, нечкә күңелле һәм бераз фәлсәфи карашлы утызлар тирәсендәге егет, каяндыр яңаклары, бусагасы

сакланып калган бер кечерәк ишек өстерәп алып кайтты да, балаларча куанып:

— Иптәшләр, әйдәгез менә бу ишекне куйыйк,— диде.— Чын йорт сыман булсын. Плащ-палаткалар белән күп яшәдек. Җитәр.

Егетләр моны хуп күрделәр. Командир, ныгытылып бетмәгән плащ-палатканы йолкып алып, туфрак коелмасын өчен түшәмгә беркетергә кушты. Сибгатуллин исә, балтасы белән каккалап-суккалап, юнасы урыннарын юнып, кисәсе җирен кисеп, ишекне землянкага җайлый башлады. Аның бу эшне бик яратып эшләве, шуның белән бергә кулыннан эш килүе балтасының йөрешеннән, юнасы, уясы урынны оста юнып, уеп алуыннан күренеп тора иде. Ишекне тәмам ныгыткач, бер ачып, бер ябып карады да, бик канәгатьләнеп:

— Менә хәзер беразөйгә охшады,— диде.

Отделениенең башка сугышчылары да, килеп, ишекне ачып, ябып карадылар, әллә ни мактамасалар да, ошаттылар, җылы озаграк сакланыр дип уйладылар.

Яктырганчы, дошман күзенә чалынмаслык чакта янып, кызып калсын дип, тимер мичне инде тергезеп җибәргәннәр, эчендәге коры агач кисәкләре, бераз төтен чыгарып, өйне, тыныч тормышны хәтерләтеп, күңелле генә чатнап яна иде. Тимер мич өстенә котелок белән чәй һәм җылытыр өчен кичтән калган бутканы да куйдылар. Снаряд гильзасыннан ясалган лампа филтәсен рәтләп, тигезләбрәк чыгардылар. Землянка эче яктырып, матураеп китте. Фронт матурлыгы, аның үзенә хас «тынлыгы», «тынычлыгы» иде бу. Чәй кайнап чыкты, бутка да җылынды, дымсу җир исе, төтен исе аңкытып торган землянкага, җанны рәхәтләндереп, аш исе, чәй исе таралды.

Егетләр (хәзергә дүртәү генә иде алар) бу тынлыкның, рәхәтнең тәмен татып калырга теләгәндәй, кружка-

ларына кайнар чәй салып алып, сәке кырыена урнаштылар, капчыкларыннан шикәрләрен, ипи кисәкләрен чыгардылар. Аларның күптән болай җылы урында, тынлыкта җыелышып утырганнары, ашап-эчкәннәре юк иде.

Сафинның да канәгатьләнүе йөзенә чыккан. Ул, чәй янына утыргач, землянка эчен тагын бер тапкыр күздән кичерде дә, канәгатьләнүен яшерә алмыйча:

— Менә тагын бер «йорт» салдык,— дип әйтеп куйды.— Торырлык. Җыйнак кына.

— Шулай, тагын бер «йорт» салдык»,— диде ефрейтор Сибгатуллин, аның сүзен кабатлап.— Чыннан да, безнең йортыбыз бу. Ничектер, землянка казып кергән саен күңелем рәхәтләнеп, җылынып китә. Яратам ла соң мин шундый күзгә күренә торган эшне. Беләсеңме нәрсә, землянка казып кергән саен үз өем күз алдыма килә. Сугыш башланыр алдыннан гына бик матур итеп йорт салган идем. Иртәгә сугыш башланасы дигән көнне туен үткәрдек. Кунаклар килде, дуслар җыелды...

Отделение командиры Сафин, араларындагы иң өлкән сугышчы, утны-суны кичкән, берничә тапкыр яраланган, үлем алдында да каушап калмаган, төз буйлы, каратутлы йөзле өлкән сержант, туып-үскән авылын, хатынын, балаларын алардан ким сагынмаса да, иптәшләренең өй, бала-чагалар турында күп сөйләшүләрен өнәп бетерми иде. Алар турында күп сөйләшсәң, сагышка бирелсәң, сагынуыңны җиңә алмасаң, солдатларның күңелләре йомшара, батырлыклары кими, сугышчан сыйфатлары начарлана дип саный иде ул. Шуңа күрә ул сүзне икенчегә борырга теләде. Әллә бәхетенә, әллә бәхетсезлегенә каршы, нәкъ шул минутта тыштан моң гына, нечкә генә бер тавыш ишетелде. Егетләр, сәерсенеп, ишеккә борылып карадылар.

— Туктагыз әле. Нәрсә бу? Нәрсә чыелдый анда?— диде Сафин.— Ишек шыгырдыймы әллә?

Кешеләр, сөйләшүләреннән туктап, тынып тордылар.

Тавыш бераздан яңадан кабатланды. Бу юлы инде аның мәче тавышы икәне ачык ишетелде. Ул инде, ишекне тырный-тырный, бик кызганыч тавыш белән елап, землянкага, җылыга кертүне сорап, ялынып кычкыра иде.

— Мөгаен, землянканы котларга килгәндер ул,— диде Сафин, елмаеп. Аның сугышчылар күңелендә туа башлаган сагышны, моңсулыкны бетерәсе килә иде.— Кертегез әле үзен. Күрик.

Сибгатуллин, урыныннан торып, ишекне барып ачты. Аннан тышкы салкын һава белән бергә, ябык кына, өтек кенә бер соры мәче килеп керде. Ул бик туңган, бөтен гәүдәсе белән калтырый, сугышчыларга карап, землянкадан куып чыгармауларын үтенгәндәй бик кызганыч тавыш белән мияулый иде.

— Мәче!— диде Сибгатуллин, бик шатланып.— Соры мәче!.. Яхшы билге бу, егетләр, валлаһи, яхшы билге! Пес-с, пес-с! Әйдә, рәхим ит, мияубикә, түрдән уз.

Мәче аның чакыруын аңламады булса кирәк, ишек төбендә баскан хәлдә, ямь-яшел күзләре белән аңа куркып карап, тынып калды. Сибгатуллин иелеп аны иркәләргә, башыннан сыйпарга теләгән иде дә, ләкин мәче, аңардан куркып, шундук бер читкә тайпылды.

Отделениедә сакал-мыек үстереп җибәргән, шуның белән бераз мактана торган, бик җылы күңелле бер чуваш егете — Василий Николаев бар иде. Мәченең кыргыйлыгын күреп, ул:

— Тимә, тимә син аңа. Бераз иялшсен, күнексен,—

диде.— Бутка бир син аңа, бутка. Тукта әле, капчыгымда колбаса кисәге бар шикелле. Шуны бирик әле.

Сибгатуллин, тимер мич өстендә торган котелоктан ике кашык бутка алып, мәче алдына салды. Хуш ис бөркеп торган бутка әле бераз кайнаррак иде, шулай да песи күзләрен солдатлардан алып, сихерләнгәндәй, буткага текәде, шиңеп төшкән колаклары тырпайды. Бик ачыккан, ябыккан, берничә көннән бирле ризык күрмәгән булса кирәк. Ахырда ул, куркуын җиңеп, буткага таба әкрен генә елышты. Бер буткага, бер сугышчыларга караштыргалап торганнан соң, ризыкка сакланып кына аягын тидереп карады. Бутка инде суына төшкән, ашарлык иде. Песи, ни булса шул булыр, үзләре биргәч, үзләре чакыргач, кыйнап үтермәсләр әле дигәндәй, тәвәккәлләп, шулай да бик шикләнеп, куркып, сугышчыларга әледән-әле күз төшергәләп алып, бутканы ашарга кереште. Землянка хуҗалары, өйне, гаиләне, тыныч тормышны хәтерләткән бу гөнаһсыз җанның землянкага килеп керүенә шатланып, ашасын, куркытмыйк дип, урыннарыннан да кузгалмыйча, хәтта тын да алмыйча, аңа кызыксынып, гаҗәпләнеп карап тора башладылар.

— Әй, песи, песи, нигә куркасың син бездән,— диде Сибгатуллин аңа.— Аша, аша, курыкма. Тимибез без сиңа... Бик кыерсытканнар булса кирәк сине. Бөтенләй кыргыйлангансың... Ярар, без синең белән дуслашырбыз әле...

Әнәс Сибгатуллинның йорт хайваннарын, мәчеләрне, этләрне яратуы, йомшак күңелле, өй җанлы кеше булуы бөтен ротага билгеле иде. Аларның телен, холкын белә иде ул. Хайваннар да аның йомшак күңелле кеше икәнен тиз сизеп алалар, аңа иялəшәләр, ышаналар иде.

Мәче алдына салган буткасын бик тәмләп, иреннәрен ялый-ялый ашап бетергәч, Сибгатуллинга карап,

нечкә, моңлы тавыш белән тагын мияулап алды. Бу аның тагын ашарга соравы иде, җитмәгән, күрәсең.

Сибгатуллин, аның белән сөйләшкән кебек, ягымлы гына итеп:

— Әй, җитмәдемени соң әле, мияубикә,— диде.— Җитмәсә, тагын салып бирәбез без. Әйдә, рәхим ит, тамагың туйсын...— дип, аңа тагын бер кашык бутка салды.

Василий Николаев та капчыгындагы колбаса кисәген алып мәчегә сузды. Төн кунагы аны да чәйнәп йотып җибәрде. Шуннан соң ул, әкрен генә, ягымлы гына мияулап, сугышчыларга тагын өтәләнеп карап тора башлады. Бу инде аның ашарга соравы түгел, ә землянкадан куып чыгармауларын үтенүе иде. Шуның белән бергә ул җылы бөркетеп торган тимер мичкә дә караштыргалап алды. Бусы инде аның мич янына барып ятарга рөхсәт соравы булды.

— Йә, нишләтәбез моны, егетләр?— диде Әхтәм Сафин, иптәшләренә карап.— Куып чыгарабызмы, әллә калдырабызмы беразга?

Егетләр куып чыгармаска, землянкада калдырырга дигән фикергә килделәр. Ни әйтсәң дә, землянка беренче сафтагы окопларда түгел, ә артта, икенче сафта. Дошман да ул чаклы борчымый, ара-тирә артиллерия һөҗүмнәре генә ясаштыргалап ала. Хәер, кайчак самолетлар да килгәләп китә. Кайберләре, землянкага яисә окопка кереп өлгермәгән сугышчылар өстенә дәһшәтле улап төшеп, пулеметлардан да атып узалар, әмма әллә ни зарар китерә алмыйлар. Шуңа күрә мәчене землянкада калдыруны барыннан да бигрәк Сибгатуллин яклады:

— Ничек итеп аны шундый салкынга, япан кырга куып чыгарасың,— диде ул.— Катып үлә бит ул анда. Снаряд яисә бомба кыйпылчыгының тиюе дә ихтимал.

Аннары шуны да уйлап карагыз, бу авылдан калган бердәнбер җан иясе бит ул. Кем белә, бәлки, әле ул безнең землянка урынында торган өйнеке дә булгандыр. Өемә кайтам, дип кергәндер, мескен. Мәче ул өеннән бизми, кая илтеп ташласаң да кайта, кайтмыйча калмый. Гадәтләрен беләм мин аларның.

Мәче, землянкадагы кешеләрнең аңа тимәвен, орышмавын, ә, киресенчә, аны иркәләргә, сыйпарга теләүләрен сизеп, шулай да әле шикләнеп, поса-поса гына мич янына үрмәләде һәм, аның артына кереп, бераз караштыргалап торганнан соң, йомарланып ятты. Шулай да күзләрен йоммады. Землянкадагы кешеләргә ышанып бетми иде әле ул. Кем белә аларны, кыйнап, куып чыгарулары да мөмкин. Сак булырга кирәк.

Бу мәченең көтмәгәндә землянкага килеп керүенә, окоп тормышын бераз үзгәртеп җибәрүенә ефрейтор Сибгатуллин аеруча куанды. Чөнки бу соры мәче аның туган авылын, өен, сандык өстендә ялкауланып йоклап ятучы шундый ук соры мәчене хәтерләтә һәм бу хәтерләтү аның җанын рәхәтләндерә иде.

Кичкә таба мәче землянкадагы кешеләргә ияләшә төште, аркасыннан сыйпата, иркәләтә дә башлады.

Бу землянкада Борис Михайлов дигән снайпер да торачак иде. Хәзергә әле ул, землянка казылган арада, башка урында ял иткәләп йөри.

Сержант Михайлов ротаның гына түгел, полкның да атаклы сугышчысы, снайперы. Алланың һәр бирмеш көнендә ул фашистларның йә берсен, йә икесен, ә кайчак уңышлы, бәхетле көннәрдә өчесен-дүртесен дөмектерә. Андый көннәрдә ул землянкага шатланып кайтып керә, ишектән килеп керү белән үк ничә гитлерчыны теге дөньяга җибәрүен белдерү өчен, уң кулын күтәреп, бармаклары белән генә күрсәтә. Егетләр аны шатланып каршы алалар, эшенең уңышлы булуы өчен куаналар,

аны ихтирам итәләр, аңа кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышалар.

Базык гәүдәле, бөдрәләнеп, тулып торган сары чәчле, соргылт күзле бу егетнең, бәхетле көннәре булган шикелле, бәхетсез көннәре дә булгалый. Бер фашистны да үтермәгән көнне ул әрәм узган бәхетсез көн итеп саный. Андый көннәрдә «ау»га чыккан җиреннән, кашларын җыерып, бик күңелсезләнеп кайтып керә. Әгәр мондый көннәр бер-бер артлы дәвам итсә, кара янып йөри, иптәшләре белән дә бик аз сөйләшә, аларның сорауларына теләр-теләмәс кенә җавап кайтара, хәтта кайвакыт мыгырданып кына ала. Иптәшләре аңа мондый көннәрдә мөмкин чаклы игътибарлырак булырга, кирәкмәгән сораулар биреп йөдәтмәскә тырышалар.

Яңа землянкага ул мәче вакыйгасыннан соң өч-дүрт көн узгач күчеп килде. Ул кергәндә ефрейтор Әнәс Сибгатуллин ут яктысында бик тырышып автоматын чистартып утыра иде. Эшен тәмамлагач, хәлен, сәламәтлеген һәм бүген эшенең ничегрәк булуын сораша-сораша, аңа булышырга кереште. Аның өчен котелокларга салып махсус китерелгән шулпаны да, бутканы да Сибгатуллин, мәче тимәсен дип, иске шинельгә төреп куйган иде. Аларны алып, җылынсын, кайнарлансын дип, янып торган тимер мич өстенә куйды. Чәе дә бар икән, аны да бераз кайнарлатып алырга кирәк тапты.

Борис Михайлов мәчене бары ашап утырганда гына күрде,— ничектер, моңача күзе төшмәгән иде аңа. Песи киптерергә элгән чолгаулар, оекбашлар арасында изрәп йоклап ята иде.

— Нәрсә бу, браток?— дип сорады ул Сибгатуллиннан.

— Нәрсә булсын, күрәсең ич, мәче,— диде ефрейтор һәм аның землянкага ничек килеп керүен сөйләп бирде.

Михайлов мәчегә тагын бер тапкыр җирәнеп карап алды:

— Яратмыйм мин мәчене. Җенем сөйми. Кемгә кирәк булды бу үләксә?

— Миңа,— диде Сибгатуллин һәм шундук өстәп әйеп куйды.— Барыбызга да.

— Нигә барыбызга да? Мине кушып санама, зинһар. Миңа кирәге юк аның.

— Аңламыйм, нигә кирәге юк аның?

— Яратмыйм, шуңа кирәге юк.

Сибгатуллинның гаҗәпләнүе йөзенә чыкты.

— Нигә яратмыйсың син аны? Файдалы хайван ич ул.

— Файдалы? Нинди файдасы булсын аның!— диде ул мыскыллап һәм шаркылдап көлеп җибәрде.— Файдалы?!. Әгәр эт булса, бер хәер иде, браток. Ау эте булса, бигрәк тә. Әйтик, лайка, яисә русская пегая гончая. Эт дисәң дә эт алар. Алар белән төлкеауларга да, бүре ауларга да чыгып була. Ә бу нәрсә!— диде ул, кашларын җыерып, җирәнеп.— Үләксә! Яхшы чакта чыгарып ташла син аны. Югыйсә бөтен землянканы пычратып бетерер.

— Пычратмас, андый түгел кебек.

— Ярар алайса, торсын,— диде снайпер, кулын селтәп.— Күрербез, нинди булыр. Шулай да пычратса-нитсә үпкәләмә, браток, атам да үтерәм мин аны.

— Фашист түгел ич ул! Мәче. Йорт хайваны.

— Пычратса, минем өчен барыбер,— диде снайпер, катгый итеп.

Сибгатуллин, күзләрен зур итеп ачып, аңа гаҗәпләнеп карап торды да, башын чайкый-чайкый:

— Йорт хайваннарына бу чаклы мәрхәмәтсез, шәфкатьсез булырга ярамый, Боря, ярамый,— диде, аны үгетләргә теләгәндәй.

Мәче, сүзнең аның турында баруын, сары чәчле кешенең аңа карата явыз ниятгә булуын сизгәндәй, әле бер күзен, әле ике күзен ачып, аларга караштыргалап ятты да, әкрен генә урыныннан торып, шикләнеп, землянка почмагына сөяп куйган винтовкалар, автоматлар артына кереп посты. Шунда яткан хәлдә ул сары чәчле кеше йокларга ятканчы аңардан күзен алмады.

Бер-ике атна эчендә мәче тәмам тазарып, матурланып китте. Ябагасы коелды, йоны шомарды, ыспайланды, сыртындагы карасу сызыгы тагын да ачыклана, ялтырый төште, койрыгы да тулыланды, ә мыеклары арыслан мыегыдай тырпаеп тора башлады. Уйнаганны, сыйпаганны ярата торган шаян мәче булып чыкты. Землянкада аны Михайловтан башка бары да яратты, аның белән уйный торган булдылар. Егетләр землянкага килеп керү белән үк ул, койрыгын таяк шикелле тырпайтып, аларга дусларча ышкына, иркәләнә, мырлый, аларның иркәләүләрен, сыйпауларын көтә.

Землянкадагы сугышчылар гына түгел, ротадагы сугышчылар да бик яратты аны. Әле берсе, әле икенчесе, аны күрергә, аны кулга алып бераз иркәләргә, сыйпаштыргаларга теләп, Сафиннар землянкасына кереп чыккалый торган булдылар. Кайчак берәрсеннән сорап, рөхсәт алып, аны үз землянкаларына да алып чыгып китәләр. Чөнки окопларга, землянкаларга тычканнар, күселәр иялəшкән иде. Әйләнә-тирәдәге авыллар яндырылып, җир белән тигезләнгәнлектән, алар, кыш көннәрендә азык эзләп, окопларга, землянкаларга саранчадай ябырылалар иде. Сугышчылар йөдәп бетә иде алардан, хәтта кайчак капчыкларындагы азык-төлекләрен яшерергә дә урын таба алмыйлар иде. Ә соры мәче тычканнарның җан дошманы булып чыкты. Бер-ике атна эчендә аларның күбесен кырып бетерде. Аның бу сыйфатын сугышчылар ихластан яраттылар. Тик Михай-

лов кына яратмады аны. Мәче дә аңа шундый ук тупас мөнәсәбәт белән җавап бирә башлады. Ул өйдә чакларда сәке өстенә менмәскә, аяк астында буталмаска тырыша. Хәтта ул снайперның кәефсез, ачулы чакларын аеруча сизә иде шикелле. Андый көннәрдә ул, землянкадан чыгып китеп, тышта йөрүне артыграк саный.

Мәче пакь, чиста, акыллы булып чыкты. Землянканы әшәкеләми, ашау-эчү әйберләренә тими. Борис Михайлов «ау»да чакта аңа дип махсус китерелгән аш белән бутка, иске шинельгә төрелгән хәлдә, авыз суларын китереп, көнозын сәкедә яисә шүрлектә торса да, аның янына да барып карамый. Чөнки ул өйдәге ашамлыкларга тиярга ярамаганын, әгәр тисәң, кешеләр моның өчен бик ачуланалар, алай гына да түгел, кыйныйлар да икәнен яхшы белә иде. Үз гомерендә аның чыраны да, чыбыкны та татып караганы шактый күп булды, аның нинди әрнүле икәнен онытмаган иде әле. Шуңа күрә ашау-эчү әйберләреннән читтәрәк булу яхшырак дип саный. Кешеләр күрмәгәндә иснәп кара да, тиз генә җылыга, тимер мич артына, киптерергә элгән чолгаулар арасына кереп ят. Сугышчылар кайтып ашарга утыргач, үзләре бирәләр, өлешсез калдырмыйлар, янындагы калай табакка ашын да, буткасын да салалар, кайчак, рәхмәт яусын үзләренә, иттән, колбасадан да өлеш чыгаралар, мәхрүм итмиләр. Мәче моңа бик канәгать. Тик сары чәчле, тәбәнәк буйлы кеше генә берни бирми — ашыннан да, буткасыннан да өлеш чыгармый, итен инде әйткән дә юк. Агулы, усал кеше булса кирәк, якын килү белән үк акырып сала. Андый кешедән читтәрәк тору хәерлерәк. Атышлар булмаганда землянкадан чыгып китү тагын да яхшырак... Атышлар башланса гына куркыныч, бик куркыныч. Мәче шулай уйлый иде булса кирәк.

Беркөнне Сибгатуллин мәченең чисталыгы, акыллы-

лыгы, землянкадагы ашау-эчү әйберләренә тимәве, хәтта орынып та карамавы турында, бик мактанып, снайперга сөйли башлаган иде, ләкин тегесе аның сүзен тыңларга да теләмәде:

— Беләм мин мәчене, беләм, күп күргән! — дип кычкырып кына салды. — Ашыңны яисә бутканы шинельгә төрмичә калдыр әле син, күрерсең шунда аның нинди әшәке җан икәнен. Сөйләмә син миңа аның турында. Җенем сөйми аны! Тик синең өчен генә чыдап торам. Син булмасаң, землянкада бер минут тотмас идем мин аны, чыгарып ыргытыр идем.

Снайперның бу фикере белән Сибгатуллин килешмәде, билгеле, ә киресенчә, мәчене мактавында, аерым алганда, бу соры мәчене мактавында дәвам итте. Дөреслек өчен шунысын да әйтик: этне дә кире какмады ул, аны да мактады, чөнки ул йорт хайваннарын, кош-кортларны, җәнлекләрне бик ярата иде.

Соры мәче акыллы, тәрбияле, чиста булса да, төннәрнең берендә, шулай да аның аркасында землянкада каты тавыш чыкты.

II

Бер төнне, отделение постта чакта, сержант Михайлов землянкага арып-талып, баштанаяк пычранып, бик күңелсезләнеп кайтып керде. Салкын тиеп, температурасы күтәрелү сәбәпле, землянкада калган Сибгатуллин, аның аяк тавышын ишетү белән үк, бүген дә эшенең уңмаган икәнен сизде. Димәк, җаена гына торырга кирәк.

Михайлов, бер сүз дә әйтмичә, винтовкасын почмакка сөяде дә маскхалаты белән шинелен салып, тимер мич янына киптерергә элеп куйды. Бераз өс-башын рәт-

ләгәч, кулын югач, капчыгыннан кашыгын алып, ашарга дип, сәке кырыена килеп утырды.

Сибгатуллин аның ашы белән буткасын җылытып, гадәтенчә, шинельгә төреп куйган икән.

— Ашың кайнардыр әле, хәзер генә җылыттым,— диде аңа.—Чәй дә бар анда. Шикәрең капчыкта. Өч көнлек.

Михайлов, бер сүз дә әйтмичә, ашы белән буткасын сузылып алып, сәкегә куйды, капчыгыннан ипиен чыгарды. Ашның кадерен белеп, тәмләп ашап бетергәч, буткасын кулына алды.

— Ә моның ите кайда?— диде ул, Сибгатуллинга карап.— Әллә бүген дә ит булмадымы?

— Булды, нигә булмасын! Ашыңдадыр.

— Анысын әйтмим, ә өстәмә паекны әйтәм.

Снайперларга, бутка өстенә салып, өстәмә ит бирәләр иде.

— Ничек белмисең син!— дип, нервланып, кычкырып җибәрде Михайлов.— Син җылыткан ич аны!

Бүген көнозын окопта, карлы яңгыр астында ятып, бер фашистны да дөмектерә алмаганга кәефе бик кырылган иде, шуңа күрә бөтен нәрсә — яңгыр да, пычрак та, караңгы төн дә, җир шүрлектә сүнәр-сүнмәс кенә янып торган лампа да, хәтта авырып ятучы Сибгатуллин да ачуын китерә иде аның.

Әнәс, аның җаена торырга теләп, тыныч кына җавап бирде:

— Бер дә игътибар итмәдем, Боря. Булмагандыр, күрәсең.

Снайпер бу җавапны да сабыр кабул итмәде:

— Ачуымны китереп, белмәгәнгә салышып утырма, зинһар!— дип кычкырып салды аңа.— Бик яхшы беләсең! Мәчең ашаган аны! Кичә дә ит булмады, бүген дә юк, иртәгә дә булмаячак! Мин бер төннән алып икенче

төнгәчә, урынымнан да кузгалмыйча, окопта ятам, фашистларны кырам. Ачыгам, туңам, чыланам, пычранып бетәм, ә монда синең үләт мәчең миңа дигән итне ашый, үзенең әшәке аякларын ашыма тыга, пычрата. Шуннан соң мин аны ашарга тиеш. Моңа кадәр тавыш чыгармадым. Аңларсың, бу чаклы миңгерәү сарык түгелсеңдер дип уйладым. Аңламыйсың икән... Ачуымны гына китерәсең. Бүген болай да ачуым чигенә җитте,— диде ул, кызганнан-кыза барып.— Ничә көн бер фашистны да тончыктыра алмыйм. Ә монда тагын синең мәчең!..

Сибгатуллин урыныннан торырга мәҗбүр булды.

— Кара әле, Боря, ул чаклы кызма әле!— диде аңа тыныч кына.— Мәчене гаепләмә син. Аның гаебе юк. Күрдең ич, ашыңны шинельгә төреп куйган идем. Аннан алып ничек ашасын ул...

Снайпер, аның сүзен колагына да алырга теләмичә:

— Әле син аны яклыйсыңмыни?!— дип ачуланып кычкырып салды.— Күрсәтим әле мин аңа! Кайда әле ул кабахәт җан?

Шул сүзләрне әйтә-әйтә, ул билендәге калын тимерле каешын чишеп алды да, ачуланып, явызланып, мәчегә таба атлады. Мәче, бу шау-шуны ишетеп, мич артына кереп поскан һәм шуннан яшел күзләрен Михайловка текәп карап тора иде.

— Ах, каһәр суккан нәрсә!— диде снайпер, аңа селтәнеп.— Син әле минем паекны ашыйсыңмы?!

Мәче аңа караганда җитезрәк булып чыкты, күз ачып йомганчы утыннар, капчыклар артына кереп посты. Снайпер анда да җитешергә уйлаган иде, ләкин Сибгатуллин үзенең зур, таза гәүдәсе белән аңа аркылы төште. Тыныч кына, кызмыйча гына аның кулындагы каешын тартып алды:

— Тукта, аны кыйнаудан файда юк! Әйтәм бит мин

сиңа: ул гаепле түгел. Тагын ни кирәк сиңа? Җүләрләнмә!

Бу каршы төшү һәм Сибгатуллинның аның кулыннан каешын тартып алуы снайперның ачуын соңгы чиккә җиткерде.

— Ничек гаепле түгел?— диде ул, зәһәрләнеп.— Менә күрсәтим әле мин аңа гаебен!..

Михайлов, ярсып, почмактагы винтовкасына сузылды, ләкин ул арада Сибгатуллин ишекне ачып җибәрде, шуны гына көткән мәче, яшендәй атылып, йөгереп чыгып китте.

— Мин аны!— диде снайпер, каты итеп сүгенеп, һәм винтовкасын кулына тоткан хәлдә, Әнәсне этеп җибәреп, бусага аша атлады.

Ул траншеяга барып чыкканда мәчедән җилләр искән иде инде.

Михайлов, землянка алдында туктап, каһәр суккан мәчене табып булмасмы икән дип, берникадәр вакыт якягына караштыргалап торды. Бөтен җир өстен кар каплаган. Айсыз төн булганга, ул да, каралып, соргылтсу булып җәелеп ята. Әйләнә-тирәдә бернәрсә күренми, хәтта өй хәрабәләре дә күренми. Бары күк йөзендә анда-санда моңсу, кайгылы йолдызлар гына җемелди. Алары да сирәк, аларны да болыт каплаган.

Алгы сафтагы окопларда сирәк-мирәк кенә атышлар бара, төнге караңгылыкны ертып, һавага яктырткыч ракеталар күтәрелә, җир өсте буйлап түбәннән генә эз калдыргыч пулялар оча. Ара-тирә орудиеләр улап ала. Аларның гөрселдәүләре, шаулары каядыр еракка, каршыдагы урманнар артына китеп югала. Шуннан соң пулемет-винтовка тавышлары тагын да ачыграк булып ишетелә башлый.

Төнге табигый күренеш, салкын җил, саф һава снайперның нервларын бераз тынычландыра төште. Хәтта

ул үзенең кинәт ярсып китүенә дә гаҗәпләнде. Боларны ул барысын да соңгы вакытларда уңышсыз үткәрелгән, аның фикеренчә, бөтенләй әрәмгә киткән, бер фашистны да дөмектерә алмаган көннәр нәтиҗәсендә туган борчылуларга сылтады. Борчылмаслыкмы соң! Күрше полктагы снайперның — Орловның счеты инде йөз уникегә җитте. Ул һәр көнне, табигый бер юлга салынгандай, бер-ике гитлерчыны, хәтта кайвакыт өчне яисә дүртне теге дөньяга озата тора. Ә аның, Михайловның, моңа кадәр дивизия күләмендә беренчелекне берәүгә дә бирмәгән снайперның, Себер егетенең, данлы аучының, счеты бик акрын үсә, җитмәсә, соңгы көннәрдә аның бер фрицны да чәнчелдергәне юк. Аның бик яшеренеп немецларны күзәтеп ятуы, кулыннан килгән барлык осталыкны, хәйләләрне куллануы,— барысы да бушка китте. Немецлар соңгы атна эчендә, үч иткәндәй, окопларыннан башларын чыгармыйлар, Михайлов пулясы алырлык участокта күренмиләр. Әгәр нинди дә булса бер чара белән аларның башларын күреп, мушкага алырга мөмкин булса, снайпер аңа әллә ни бирер иде. Юк, ул дошман солдатын үтермичә, аны дөньяга җибәрмичә яши алмый. Фашистны мушкага алмаган көн — аның өчен бушка, әрәмгә узган көн.

Озакламас, бер атна, күп дисәң ике атна чамасы вакыт узар, снайпер Орлов теге дөньяга җибәргән фашистлар саны белән аны куып җитәр, хәтта, узып та китеп, дивизиядә иң алдынгы снайпер булып санала башлар...

Менә шуңа борчыла Михайлов. Моны берәүгә дә әйтмичә, эченнән яна. Җитмәсә тагын каяндыр каһәр төшкән бу мәче килеп чыкты. Әгәр ул булмаса, аның ачуы да бу чаклы ярсып, ташып чыкмаган булыр иде.

Михайлов землянкага кире кереп ятарга әзерләнгәндә, бик ашыгып кына рота старшинасы килеп керде.

— Менә нәрсә, иптәш сержант,— диде ул снайперга.— Күргәнсең, кичә дә, бүген дә өстәмә ит булмады сиңа. Шуның өчен мин сиңа ит консервасы китердем.— Бөрмәле капчыгыннан алып, аның кулына бер калай банка тоттырды. Хәлен, сәламәтлеген сорашырга теләгән иде дә, ләкин Михайлов аңа мыгырдап кына җавап кайтарды. Чөнки ул әле генә булып үткән вакыйга өчен, кирәкмәгәнгә тавыш чыгаруы, Әнәскә каты сүзләр әйтүе, барыннан да бигрәк, винтовкасын күтәреп, снайпер башы белән, оялмыйча мәче артыннан траншеяга йөгереп чыгуы өчен үкенә, үзен гаепле саный иде. Шуңа күрә аның берәү белән дә, хәтта старшина белән дә сөйләшәсе килми. «Нервларым бик какшаган, бик какшаган,— дип уйлады ул үзе турында.— Барысы да шул, эшемнең уңышсызлыгы аркасында...»

Старшина, аның кәефе юклыгын сизеп, авыруга таба борылды:

— Ә синең хәлләр ничек?— диде ул, Сибгатуллин янына барып басып. Сөялле кулы белән аның маңгаен тотып карады:— Бар икән әле температураң, бар икән. Шаять бер-ике көннән терелерсең. Берәр нәрсә кирәкмиме үзеңә? Әйтик, селедка, шуның кебек нәмәстә. Авыз тәме өчен дип әйтүем. Ә?.. Теләсәң, мүк җиләге дә табарга була. Сазлыкта бар. Кирәк булса, иртәгә берәрсен җибәрәм, җыеп алып кайтыр.

Сибгатуллинга бернәрсә дә кирәкми икән, старшинага рәхмәтен әйтеп, аның өчен кешеләрне мәшәкатьләмәвен үтенде. Үзең дә мәшәкатьләнмә, зинһар, диде.

Старшина чыгып киткәч, Сибгатуллин, атышларга колак салгалап, озак уйланып ятты. «Нигә инде старшина белән шулай тупас сөйләшергә?— диде ул күңеленнән Михайлов турында.— Снайпер булсаң да, ярамый. Мин түгел ич ул. Ә старшина. Минем белән теләсә ничек сөйләш. Аннары мәчене... Нигә кыерсытырга иде

инде аны... Ярамый болай, ярамый...» Ята торгач, Сибгатуллин, шулай уйланып, йокыга киткән сыман булды.

...Снайперның шуннан соңгы көннәре дә уңышсыз булып чыкты. Ул инде бөтенләй күңелсезләнеп, каралып, эченнән янып йөри башлады, хәтта кеше белән дә сөйләшмәс булды. Рота командиры белән батальон командиры да, аны үзләре янына чакырып алып, уңышсызлыкның сәбәбен җентекләп сораштылар. Иптәшләре дә егетнең бу хәлен күреп торалар, аны мөмкин кадәр тынычландырырга тырышалар. Сибгатуллин исә кайчак мәчене, аңа күрсәтмәс өчен, кич белән күрше землянкаларның берсенә кертеп куя торган булды.

— Тәмам башым катты,— диде Михайлов, беркөнне иптәшләренә.— Һич тә хәйлә таба алмыйм. Никадәр вакыт узды, ә счетым һаман бер тирәдә. Оят, валлаһи!.. Фрицлар нигә шул хәтле посып яталар? Берничә секундка гына булса да башларын күрсәтсеннәр иде. Көнозын күзәтеп ятасың, туңып, өшеп бетәсең, ә окоптан бер немецның да башы күренми. Ни булды аларга?

Егетләр аңа, карачкы ясап, фашистларны шуның белән алдарга тәкъдим иттеләр.

— Юк, хәзер аның белән алдап булмый аларны,— диде снайпер, кулып селтәп.— Авызлары пешкән аларның. Беләләр, сизәләр.

Шуннан соң аңа дуслары консерва тартмалары, көзге һәм башка шуның кебек нәрсәләр белән хәйлә оештырырга киңәш итеп карадылар. Ләкин снайпер аларны да кире какты, чөнки инде ул алардан файдаланган һәм шулай итеп берничә гитлерчыны дөмектергән иде.

Сибгатуллин бер читтә тәмәкесен тарта-тарта үзүзенә уйланып утыра иде.

— Бәлки, мәче белән берәр нәрсә эшләп булыр,— диде ул, җитди итеп.

— Нәрсә? Мәче беләнме?— диде Михайлов аңа, мыскыллап карап.

— Әйе, мәче белән.

Снайперның соргылт күзләре кинәт зәһәрләнеп китте:

— Синең үләтең ул землянканы пычратырга гына ярый. Ачуымны китереп, шаяртып утырма! Болай да башым каткан!.. Ташла!.. Тагын бер тапкыр мәчеңне телгә алсаң, валлаһи дип әйтәм, атам да үтерәм мин аны! Үзең беләсең, ике әйтә торган гадәтем юк!

— Нигә атарга аны?— диде Сибгатуллин аңа каршы тыныч кына.— Мин бит сиңа чынлап әйтәм. Яхшылык итәргә телим. Бәлки, аның белән берәр хәйлә корып булыр... Мәсәлән, үзең уйлап кара...

Әмма снайперның уйларга да, Әнәснең сүзен тыңларга да исәбе юк иде:

— Ташла, зинһар, башымны катырма әле шул үләтең белән!— дип, ул Сибгатуллинга тагын бер тапкыр кычкырып салды.

Сибгатуллинның йөрәген нидер бик каты чеметеп алды, йөзенә дә кинәт кан йөгерде, хәтта куллары да калтырый башлады. Шулай да ул, землянкада, иптәшләре арасында тавыш чыгармас өчен, үзен көч-хәл белән тыеп тотып, мәчене кулына алды да шинелен иңенә салган хәлдә генә, дагалы итеге белән каты-каты басып, траншеяга чыгып китте. Чөнки ул кайда гына булмасын,— казармадамы, резервтамы яисә окоптамы, барыбер,— сугышчан иптәшләренең бердәм, тату, дус яшәүләрен тели һәм коллективта мөмкин чаклы тынычлыкны сакларга тырыша иде. Үзара дуслык, татулык булганда атакага да батыррак барасың, дошман траншеясына да кыюрак сикереп төшәсең дип уйлый иде. Иптәшләренә, дусларына чын күңелдән ышана иде ул. Әгәр аңа берәр авырлык килсә, иптәшләре, дуслары яр-

дәмгә киләчәкләр, аны ялгыз калдырмаячаклар. Ә ул үзе, иптәшләреннән берәрсе көтелмәгән бәлага очраса, иң беренче булып аңа ярдәмгә бара, аны ут астыннан да, дошман тырнагыннан да йолып ала... Иптәшләре арасындагы дуслыкны, бердәмлекне ул күз карасыдай сакларга тырыша.

Траншеяга чыккач, ул, мәчесен күкрәгенә кысып тоткан хәлдә, бер карарга килә алмыйча, берничә минут уйланып басып торды. Төн караңгы, күк йөзен кара болыт каплаган. Тик алгы сафтагы окоплар өстендә генә яктырткыч ракеталар, зәңгәрсу нурларын җир өстендә сирпеп, әледән-әле һавага күтәреләләр. Атышлар да сирәк. Пулеметлар яисә ялгыз винтовкалар, үзләренең дөньяда барлыгын, үлем таләп итүләрен белдерергә теләгәндәй, анда-санда гына шаулап алалар.

Михайловка үпкәсе зур иде Әнәс Сибгатуллинның. «Менә бит син аны!— диде ул авыз эченнән генә.— Мин аңа яхшылык итмәкче булам. Ә ул кычкыра, акыра, хурлый... Әйтерсең мин кычкыра белмим... Минем дә авызым бар, тамагым бар... Аннан да катырак кычкыра алам мин. Тик кычкырмыйм гына. Сугышта кычкырышырга ярамый. Тату яшәргә кирәк, дус яшәргә кирәк. Сугыш бит ул! Сугыш! Шулай бит, песекәй?»— диде ул, зур, кытыршы, сөялле кулы белән мәченең башыннан сыйпап. Мәче, аның үз-үзенә пышылдап кына әйткән сүзләрен, күңел кичерешен, сагышын аңлагандай, аңа сыена, иркәләнә һәм әкрен генә, ишетелер-ишетелмәс кенә мырлый иде.

Шулай бераз уйланып басып торганнан соң, Сибгатуллин мәчене күрше землянкаларның берсенә кертеп бирде:

— Сездә кунсын әле бу,— диде ул андагы егетләргә.— Тик чыгып китә күрмәсен. Саклагыз!

Яшь солдатлар урнашкан иде бу землянкага. Мәче-

не алар бик шатланып алып калдылар. Хәтта берсе, урыныннан торып, аны кулына алды да, шинеле белән каплап, кочып ятты.

Ә бу минутларда землянкада калган өлкән сержант Әхтәм Сафин белән чуваш егете Василий Николаев снайперны иптәшләрчә шелтәлиләр иде.

— Нигә кычкырасың син аңа?— диде Әхтәм Сафин.— Нигә акырасың? Ул бит сине хурлап, кимсетеп бер сүз дә әйтмәде... Бары мәче турында гына нидер әйтергә теләде. Кем белә, бәлки, берәр файдалы киңәше булгандыр... Сүзенә колак салырга кирәк иде. Ярамый болай, Боря, ярамый! Бер землянкада торабыз ич. Бер коллектив кешеләре. Бер-береңне ихтирам итәргә кирәк.

Чуваш егетенең дә әйтәсе сүзе бар икән.

— Ә син, Борис Захарович, кемгә кычкырганыңны беләсеңме? — диде ул, снайперның күзенә керердәй булып.

— Кемгә булсын, Сибгатуллинга кычкырдым. Мәчесе белән башымны катырып утырмасын,— дию белән генә чикләнде Борис Михайлович.

— Ә син аның кем икәнен беләсеңме?— диде Николаев, сүзен дәвам иттереп.

— Кем булсын, ефрейтор! Борчылма, укалары коелмас. Коелса да, берни түгел.

— Белмисең икән шул аның кем икәнен,— диде Николаев.— Белмисең икән! Белсәң, кычкырмас идең син аңа. Телең әйләнмәс иде.

Снайпер аңа гаҗәпләнеп карады:

— Нигә?

— Ротадагы иң батыр солдатларның берсе бит ул. Менә кем ул! Атакага барганда окоптан беренче булып кем атылып чыга? Ул атылып чыга. Ротаны атакага кем иярттеп бара? Күп очракта ул иярттеп бара. Дошман

траншеясына да беренче ул сикереп төшә. Менә нинди кеше ул! Ә син аның дошман траншеясында ничек сугышканын күргәнең бармы? Күргәнең юк шул менә... Күрсәң, аның алдында бүрегеңне салыр идең син... Менә нинди сугышчы ул безнең Әнәс Сибгатуллин!

Рядовой Николаев куркуны белмәс кыю солдатларны олылый, ихтирам итә, аларның шашкын батырлыкларына кызыга һәм шундый сугышчылар белән бер сафта булуы белән горурлана да иде. Үзенең дә шулар шикелле буласы килә иде аның. Ул, әйтәсе сүзен әйтеп бетерергә теләп, сүзен дәвам иттерде:

— Рота командиры да, аның белән икәүдән-икәү сөйләшкәндә, этисе исеме белән олылап, Әнәс Абдуллович дип эндәшә аңа. Ә син кычкырасың, акырасың аңа...

Снайпер, үзен яклап, бәхәсләшеп карася да, хаксызлыгын тиз төшенде:

— Нишлим соң, егетләр, аптыраганга кычкырып салдым,— диде ул, кулын селтәп.— Кызмаска кирәк иде, билгеле. Нишлисең бит, башым катты, аптырадым... Ә ул мәчесе белән килеп тыгыла. Ни пычагыма кирәк ул миңа! Билләһи яратмыйм мин мәчене! Җенем сөйми. Эт булса бер хәер иде. Ул чакта ачуым да кузгалмас иде. Ә ул үзенең үләте белән...

Егетләр, сүз куешкандай, бер үк сүзне әйттеләр:

— Синең мәче түгел ич ул! Рота мәчесе. Күрдеңме никадәр тычканны, күсене кырып салды ул. Югыйсә тәмам йөдәгән идек. Рәхмәт әйтергә кирәк аңа. Ә син аны атып үтермәкче буласың... Нинди хакың бар синең аны үтерергә?

Михайловның әйтерлек сүзе калмаган иде инде. Ул, кулын селтәп, иптәшләренең бу турыда артык сөйләшмәүләрен үтенгәндәй:

— Нервым бик какшаган минем, нервым,— дип, сүзеннән туктады.

Рядовой Николаев чәйгә дип тимер мич өстенә ике котелок су куйган икән. Бәхәсләшкән арада кайнап та чыкты. Шуларның берсенә ул, бөрмәле капчыгыннан алып, кадерен белеп кенә бөртекле чәй салды да кашыгы белән бераз болгаткалап торганнан соң котелокны, бияләе белән тотып, җир сәке өстенә китереп куйды:

— Әйдәгез, баһадирлар, чәйгә рәхим итегез!—диде ул, иптәшләренең күңелләрен күтәрер өчен беркадәр шаярып.— Сугышта йөри-йөри каралып, ямьшәеп беткән кружкаларыгызны тотыгыз. Мәскәүнең иң яхшы рестораннарында гына эчәргә мөмкин булган хуш исле чәй салып бирәм мин сезгә. Туйганчы эчегез! Күңелләрегез күтәрелеп китсен!

Бу шаяру, иптәшләрчә җылы мөнәсәбәт, хуш исле кайнар чәй егетләр күңеленә үрмәли башлаган киеренкелекне кинәт таратып җибәрде. Алар капчыкларыннан шикәрләрен, ипиләрен чыгардылар, кружкаларын кулларына алдылар. Чыннан да чәй кайнар, тәмле, хуш исле икән. Хәтта бу хуш ис землянкага да таралды.

Әхтәм Сафин, кружкасын кулына алып, чәен татып карады да, иптәшләренә мөрәҗәгать итеп:

— Без әле генә мәче турында бераз бәхәсләшеп алдык,— дип сүз башлап җибәрде.— Аны файдалы, файдасыз хайван дип тә атадык. Шулай да әйтегез әле миңа: сезнең кайсыгыз мәченең моннан ничә мең ел элек кешеләргә ияләшә башлаган икәнен белә?

Бу сорауны ишетү белән үк снайпер, яңадан кашын җыера төшеп, кулын селтәде:

— Әй, ташласана шуны! Нигә кирәге бар аның? Ә менә эт турында сорасаң, анысын әйтә алам.

— Туктагыз әле, Борис Захарович,— диде чуваш егете, аның сүзен бүлеп.— Бик кызыклы мәсьәлә бу.



Чыннан да, кешеләргә кайчан ияләшә башлаган икән ул?

Сафин отделениедә иң белемле, иң күп укучы сугышчыларның берсе иде. Кайчак ул тарихка, географиягә, әдәбиятка, фән-техникага һәм башка фәннәргә бәйләнешле кайбер кызыклы мәгълүматларны ял вакытларында иптәшләренә сәгатьләр буенча сөйләп утыра ала иде. Шуңа күрә Михайлов та тискәреләнеп тормады, тыңларга әзер икәнен белдереп, соргылт күзләрен Сафинга юнәлтте:

— Белсәң, әйт, кайчан ияләшә башлаган?

— Галимнәрнең язуларына караганда, моннан биш мең еллар элек ияләшә башлаган ул кешеләргә. Борынгы Мисыр халкы аны, ягъни мәчене, изге хайван итеп санаган. Үлгәннән соң черемәсен, бозылмасын өчен, бәлзәмләп, саркофагка салып күмгәннәр. Фиргавеннәр һәм колбиләүчеләр, ягъни шул замандагы зур байлар мәченең үзен дә, шулай ук саркофагны да алтын-көмеш, энҗе-мәрҗәннәр белән бизәгәннәр. Менә шулай кадерләп, олылап күмгәннәр анда мәчене.

— Нәрсә соң ул саркофаг?— дип сорады чуваш егете. Һәр ишеткән яңа сүз белән кызыксына, аның мәгънәсен белергә тели иде ул.

— Саркофаг ул борынгы замандагы таш табут,— дип җавап бирде дә, Әхтәм Сафин сүзен дәвам иттерде:— Мәчеләр өчен махсус зиратлар да булган аларда. Моннан күп еллар элек археологлар Нил елгасы буендагы ниндидер бер шәһәр хәрабәләре янында шундый бер зират тапканнар. Йөз меңнән артык мәче күмелгән булган анда.

Михайлов, бу гаҗәп мәгълүмат белән кызыксынса да, отделение командирының сүзен бүлеп, бу хакта үз фикерен әйтмичә булдыра алмады:

— Тапканнар изге хайван! Бу чаклы да надан, то-

мана булганнар икән! Борынгы Мисыр халкын әйтәм. Әүзләре киләчәк буыннарга нинди пирамидалар, сфинкслар, архитектура памятниклары калдырганнар. Этне изге хайван итеп санасалар бер хәер иде.

— Кем белә, бәлки, кайда да булса этне дә изге хайван итеп санаганнардыр,— диде Әхтәм Сафин, аның фикере белән килешкәндәй.— Ихтирамга бик лаеклы хайван ул. Кайбер илләрдә тикмәгә генә һәйкәлләр куелмаган аңа. Мәсәлән, Канар утрауларында. Сәяхәтчеләрнең язуларына караганда, этләрне ихтирам итеп куелган һәйкәлләр күп икән анда. Мәйданнарга, паркларга, хәтта зур урамнарга да куелган дип язалар. Аннары «Канар» сүзенең мәгънәсенә игътибар итегез. Латинча «эт» дигән сүз ул. Шулай булгач, Канар утраулары Эт утраулары дигән мәгънәне аңлата.

Моны бик кызыксынып тыңлап утырган снайпер:

— Белмисеңме, нигә ул хәтле күп икән анда һәйкәлләр?— дип сорады.— Этләргә дип әйтүем.

— Сәбәбе булгандыр күрәсең. Бала чакта мин бу турыда бер китап укыган идем. Авторы хәтеремдә калмаган. Хәер, ул чакта китапларның авторларына игътибар итми идем. Бары эчтәлекләре генә кызыклы булсын. Шул җитә. Менә шул китапта бу турыда болайрак язганнар иде. Имеш, европалылар, испаннар булса кирәк, Канар утрауларына беренче булып аяк басканнар. Шунда этләрнең күплеген күреп, бик гаҗәпләнгәннәр. Җитмәсә вак этләр түгел, ә эре-эре этләр. Утрауларга беренче булып аяк баскан кешеләр башта бу этләрдән бик шикләнгәннәр. Этнең гадәтен үзең беләсең. Ул хакта сиңа сөйләп торуның кирәге юк. Күп тә узмаган, этләр тиз арада әлеге кешеләрнең, сәяхәтчеләрнең дип әйтүем, тугрылыклы дуслары, ярдәмчеләре булып әверелгәннәр... Яңа җирләрне ачканда булсын, ауда бул-

сын, хуҗалыкларны саклауда булсын, бар эштә дә кешеләргә ярдәм итә башлаганнар.

— Хәзер нихәл икән анда? Этләргә әле дә һәйкәл куялармы икән?

— Анысын әйтә алмыйм. Хәтеремдә калмаган. Күптән укыган идем мин ул китапны.

— Кайда соң ул Канар утраулары?

— Атлантик океанда. Африка ярларыннан төньяк-көнбатышта.

— Еракта икән. Үз илебездә булса, сугыштан соң валлаһи барып карар идем.

— Советлар Союзында да бар андый һәйкәл.

— Кайда?

— Ленинградта, Павлов* исемдәге эксперименталь-медицина институты ишегалдында.

Снайпер Михайлов, җанланып, бөтенләй ачылып китеп:

— Һай, ул эт дигән хайванны мактап бетерерлек түгел!— дип кычкырып әйтеп куйды.— Мәсәлән, овчарканы гына алып карыйк. Менә эт дисәң дә эт! Хуҗасына шул дәрәҗәдә тугрылыклы, әйтеп бетергесез! Өеңне сакларга куясың икән — капкаңны да, ишегеңне дә бикләмә. Чит кешене кертмәс. Кертсә, чыгармас. Аның исне тоюы, шылт иткән тавышны да ишетүе, нервысының ныклыгы турында әйтеп тә тормыйм. Моны үзегез дә беләсез. Тагын колли дигән эт бар. Ул да шәп. Әмма овчаркага тормый. Мин үзем, аучы булганга, ау этләрен барысыннан да артыграк күрәм. Затлы нәселдән туган этләрне күргәнегез бармы сезнең? Мәсәлән, лайканы, бурзайны, английский сеттер-

---

*Павлов Иван Петрович (1849—1936)— мәшһүр галим, академик, физиолог; күп кенә илләр академияләренең, университетларының һәм фәнни оешмаларының почетлы члены.

не, спаниельне яисә фокстерьерны. Кыскасы, чын ау этләрен? Әй, яратам ла соң аларны! Хәер,— диде аннары ул, бераз уйланып торгач,— өйрәтелгән этләрнең барысы да яхшы. Ниләр генә эшләми алар! Кешегә ничек кенә ярдәм итми. Фронттагы этләрне генә алып карыйк. Дошман танкларын шартлаталар, күмелгән миналарны эзләп табалар, шпионнарны эзәрлеклиләр, яралыларны сугыш кырыннан тартып алып чыгалар... Кыскасы, аларның файдалы хезмәтләрен санап бетерерлек түгел. Саперлар ротасында яисә этле санроталарда булганыгыз бармы сезнең?..

Иптәшләре аның сүзен бүлдермәделәр, шикәрләрен тешләре белән шартлатып китеп, кайнар чәй эчә-эчә, тыңлап утырдылар. Соңгы кружканы эчкәннән соң гына Сафин, аның сүзен бүлеп:

— Сизәсеңме, Боря, этләр турында сөйли башласаң, бөтен нәрсәне онытасың син,— диде аңа.— Ашарга да бирмә сиңа, этләр турында гына сөйләтеп утыр. Чәеңне кара. Суынды бит.

— Ах, чорт возьми, чыннан да суынган икән!— дип, шаркылдап көлеп җибәрде снайпер.— Этләрне бик яратам шул мин!

Иптәшләре дә аның белән бергә көлештеләр.

Әнәс Сибгатуллин землянкага әйләнеп кайтканда, егетләр, утны сүндереп, йокларга ятканнар иде инде. Әнәс караңгыда капшанып үз урынын тапты да, җир сәкегә менеп, чишенмичә генә сузылып ятты.

Николаев йокыга китмәгән икән. Ул, йоклаучылар уянмасын, дип дустының колагына пышылдады:

— Тимер мич өстендә кайнар чәй бар. Эч.

Әнәс тә пышылдап кына җавап кайтарды:

— Рәхмәт, эчәсем килми.

III

Өлкән сержант Әхтәм Сафиннар взводы, төнлә белән алгы сызыкка барып, снайперлар өчен төрле урыннарда,— әрәмәлекләр арасында, таучык җирләрдә — кыскасы, дошман траншеясындагы хәрәкәтне күзәтергә мөмкин булган уңай урыннарда, бик сакланып, яшеренеп, бер атна чамасы окоплар казыды. Аларны багланыш юллары белән тоташтырдылар. Һәр казылган җирне әйләнә-тирәдәге кар белән, чыбык-чабык белән томалап, бик тырышып маскировать иттеләр.

Казуы ансат булмады. Кар бераз йомшара башлаган сыман булса да, җир таш кебек каты иде әле. Көрәк белән генә түгел, кәйлә белән дә казуы читен иде. Әхтәм Сафинның образлы сүзе белән әйткәндә, алар аны казымадылар, ә тешләре белән кимерделәр. Анна-ры дошманның яктырткыч ракеталары да тынгылык бирмәде, өзлексез дип әйтерлек һавада асылынып торды. Алар һавага күтәрелү белән үк, сугышчылар, җиргә капланып, тыннарын чыгармыйча ятарга мәҗбүр булалар иде. Полктагы үзешчән рәссамнарга рәхмәт, алар фанер такталардан кораштырган ышыклангычларны җитәрлек әзерләделәр. Ерактан караганда, дошман күзенә аларның кайберләре кар сыман булып, ә кайберләре окоплар тирәсендәге сагышлы, моңсу куаклардай булып күренә иде. Күп урында сугышчылар окопларны, багланыш юлларын шундый такталар белән ышыкланып казырга мәҗбүр булдылар.

Снайпер Борис Михайлов бик зур читенлек белән казылган окопларны, багланыш юлларын ошатты булса кирәк. Чөнки ул тирәгә беренче тапкыр баруыннан ук бик канәгать булып кайтты. Егетләр моны аның землянкага ничек кайтып керүеннән, тавышыннан, хәтта күз карашыннан ук сизеп алдылар. Хәер, үзе дә,

ишектән килеп керү белән үк, электәге гадәтенчә, уң кулын күтәреп, өч бармагын күрсәтте. Өч фашистны дөмектердем дигән сүзе иде бу аның. Землянкадагы иптәшләренең дә күңелләре күтәрелеп китте.

Шул көннән башлап снайпер, яңадан туган шикелле, тәмам үзгәрде, шатланып, рухланып йөри башлады, иптәшләренә булган мөнәсәбәте дә яхшырды, хәтта мәчегә дә акырмый, кычкырмый торган булып китте. Әгәр ашап утырганда мәче, каян булса да кайтып, землянкага килеп керсә, ул аңа йә буткасыннан, йә итеннән өлеш чыгарып, аның тимер мич янындагы калай табагына илтеп сала, «Кес-с, кес-с!» дип әйтеп, аны ашарга чакыра. Тик мәче генә аның бу үзгәрешен аңламады, әллә инде аңларга теләмәде. Чөнки ышанмый иде ул аңа. Снайпер аны табак янына никадәр чакырса да, мәче урыныннан кузгалмады, табак янына бармады, ә почмакта посып утыруны артыграк күрде. Бары снайпер землянкадан чыгып киткәч кенә ул табак янына барырга батырчылык итә. Анда да әле снайпер салган азыкны курка-курка гына ашый.

Хәер, бу көннәрдә соры мәче, землянкада утыруга караганда, тышта, һавада сәйран кылып йөрүне артыграк күрә. Чөнки яз фасылы кереп, кояш җылыта башлаган иде инде. Көндезләрен ул хәрабәләр арасында нидер эзләп, иснәнеп йөри, йә берәр агач башына менеп кунаклый, яисә берәр уңайрак, корырак урын табып, шунда сузылып ята. Ә төннәрен, землянкадан чыгып китеп, борчылып, мыраулап йөри, кемнедер эзли, кемнедер үз янына чакыра, юксына...

Снайперның мәчегә акырмый-кычкырмый башлавын землянкада иң беренче булып рядовой Николаев сизеп алды. Беркөнне ул көндез, снайпер «ау»да чакта, Әнәс Сибгатуллинга:

— Күрәсеңме снайперны, үзгәрә бит,— диде.

— Ничек үзгәрә?

— Сизмисеңме әллә? Мәчегә акырмый, кычкырмый башлады... Кайчак ашарына да сала. Тик мәче генә...

Сибгатуллин аңа, мыек астыннан гына елмаеп, җавап кайтарды:

— Ашарына биргәли бирүен. Анысы дөрес. Тик мәчене барыбер яратмый ул.

— Каян беләсең син аны?

— Мин түгел, мәче белә. Мәче сизә.

— Ничек белә соң ул аны?

— Күрмисеңмени, ул биргән азыкны аның алдында ашамый. Ә ул чыгып киткәч кенә ашый. Анда да курка-курка гына.

— Анысы дөрес. Курка әле мәче аннан.

— Снайперның күңеле йомшара башлаган икән, димәк, аның сәбәбе бар,— диде Әнәс.— Аңлыйсыңмы, сәбәбе бар... Фрицларны тончыктыра ул хәзер. Шуңа куанып йөри ул. Мәчегә дә ул чаклы ачуы килми аның хәзер. Хикмәт менә шунда, Вася, шунда.

...Апрель ае кереп, җир кибә башлаган иде инде. Шадра кар чокыр-чакырларда, урман арасында һәм кояш төшми торган күләгәле җирләрдә генә калып бара. Шундый көннәрнең берендә траншея буенда постта торучы рядовой Василий Николаев арттан, тыл ягыннан аларга, ягъни икенче сафтагы окопларга таба сызылган юл буйлап килүче ике кешене күреп алды. Еракта иде әле алар, карамчык шикелле генә күренәләр иде. Шулай да ул бераздан аларның бер хатын белән бер малай икәнен шәйләде. Бу тирәдә җирле халыкка йөрергә рөхсәт юклыгын белмиләрме әллә? Нишләп йөриләр алар монда?

Хатын белән малай инде ачыграк күренә башлады.

Нишләргә? Винтовкадан атып, сигнал биреп, куып җибәрергәме әллә үзләрен? Бу тирәдә айкалып йөрмәсәннәр, китсеннәр... Миналы җиргә барып кереп, харап булулары мөмкин...

Николаев шулай икеләнеп уйлап торганда, аның бәхетенә каршы, рота командиры өлкән лейтенант Шәйхуллин траншея буйлап узып бара икән.

— Иптәш өлкән лейтенант, рөхсәт итегез сезгә мөрәҗәгать итәргә,— диде аңа рядовой Николаев. Рөхсәт алгач, бер хатын белән бер малайның аларга, икенче сафтагы окопларга таба килүен әйтте:— Нишләргә боерасыз? Куып җибәримме? Әллә килсеннәрме?

Өстен-башын һәрчак җыйнак, пөхтә итеп йөртүче һәм үз кул астындагы сугышчылардан да шуны таләп итүче егерме биш-егерме җиде яшьләр чамасындагы бу төз буйлы, күрер күзгә матур кыяфәтле командир, траншеядан җиңел генә сикереп чыгып, рядовой Николаев янына килеп басты:

— Кайда?

Постта торучы егет авылга таба түбәннән, урман ягыннан килә торган юлга төртеп күрсәтте:

— Әнә теге юлда... Күрәсезме ике кеше монда таба килә. Бер хатын белән бер малай.

Командир биноклен күзенә китерде:

— Күрәм. Бу тирәдәге авыл кешеләре булса кирәк. Тетелгән кием-салымлылар.

— Нишлим? Барып, куып җибәримме үзләрен?

— Ашыкма. Бераз көтик. Бәлки, безгә таба килми торганнардыр. Алдарак сулга таба тагын бер юл бар. Шул юл белән китмәсләрме?

Рядовой Николаевның күзе үткен икән.

— Безгә таба киләләр алар,— дип кырт кисеп әйтте.

— Каян беләсең аны?

— Кулларын каш өстенә куеп, безнең якка караштыргалап алалар.

Солдат сүзе дөрес булып чыкты. Бераздан бер малай белән бер хатын, сазлы юл пычрагын ерып атлап, көч-хәл белән диярлек авыл башына килеп җиттеләр, бер нигезне уздылар, икенче нигезне уздылар, ә өченче нигез янында туктап, бер мәлгә катып калдылар. Хатын иске, ертык шәленең чите белән берничә тапкыр күз яшен сөртеп алды, ә малай исә битен җиңе белән генә сыпырды.

— Үз нигезләре янына килеп туктадылар ахры,— диде командир.— Елыйлар.

Николаев бер сүз әйтмәде. Алар әллә ни якында булмаса да, ул барысын да күреп тора иде. Малайның башындагы колаклы бүреге дә, өстендәге озын җиңле сырмасы да, хәтта аягындагы күн итеге дә ачык күренә аңа. Хатын өстендәге кием дә шактый киелгән, тузган булса кирәк.

— Бар, чакыр әле аларны бирегә,— диде өлкән лейтенант рядовой Николаевка.— Кемнәр икән? Нишләп йөриләр монда?

— Була, иптәш командир!— диде дә Николаев приказны үтәргә йөгерде, әмма Шәйхуллин аны шундук туктатты:

— Йөгермә! Әкрен генә бар! Куркытырсың.

Траншеядан бер читтә, авылга табарак җирдә, киселгәннән калган берничә нарат төбе бар иде. Шәйхуллин шуларның берсенә барып утырды да, һавага карап алды. Күк йөзе тыныч, дошман самолетлары күренми,— димәк, килүчеләр белән монда сөйләшеп утырырга була. «Шулай да землянкага алып керү хәерлерәк булыр аларны,— дип уйлап алды ул шундук.— Дошман артиллериясенең ут ачуы мөмкин».

Берничә минуттан рядовой Николаев хатын белән малайны аның янына ияртеп алып килә иде инде.

Барыннан да элек Шәйхуллин нигәдер малайга, аның әнисе артыннан калышмаска тырышып, авыр-авыр атлап килүенә игътибар итте. Малай зур түгел, унике-унөч яшьләр чамасында гына. Башында йоны кырылып беткән иске малахай бүрек, өстендә солдат сырмасы. Ул аның сөяктән генә гыйбарәт гәүдәсендә таякка эленгәндәй салынып тора. Җиңнәре озын. Аягында күпне күргән солдат итеге булса кирәк. Шуңа авыр атлый торгандыр.

Малайның ябык, саргылт йөзе өлкән лейтенант күңелен аеруча җәлеп итте. Чөнки анда тел белән әйтеп, аңлатып бирергә мөмкин булмаган ниндидер картлык чалымы бар иде. Шуның белән бергә, бу нәни җанның бөтен торышыннан, кыяфәтеннән ачлыкны, мохтаҗлыкны, хәвефле, дәһшәтле көннәрне кичергәнлеге дә сизелеп тора. Тик күзләре генә тере. Хәтта уттай яна. Күңелендәге куркуны, шикләнүне җиңеп, әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсәгә, сугышчыларга, дзотларга, ут позицияләренә гаҗәпләнеп карый. Әгәр кулына автомат яисә винтовка тоттырсаң, бер минут та икеләнеп тормыйча, солдатлар янына барып басар һәм моңа бик шатланыр шикелле.

Әнисенең күзләре моңсу, хәсрәтле. Нигәдер ул бөтен нәрсәгә куркып, шикләнеп карый. Бу курку, шикләнү аның ябык, саргылт йөзенә чыккан. Үзе утыз бишләр тирәсендә генә булса да, чәче яртылаш агарган, яңаклары суырылып кергән, хәсрәтле күзләре эчкә баткан. Болар барысы да ачлы-туклы үткәргән авыр, дәһшәтле еллар билгесе, аның мәрхәмәтсез мөһере булса кирәк.

Фронт буенда ук булган туган-үскән авылга бик куркып, шикләнә-шикләнә килгәннәр иде алар. Дәһ-

шәтле хәрабәне тагын бер тапкыр күргәч, ана белән баланың кайгы-хәсрәтләре яңадан кузгалып, үзәкләре өзелеп киткән иде. Икесенең дә, туган өй нигезенә ятып, аны кочып, кычкырып, үкереп елыйсылары килә иде. Җаннары тетрәп, күңелләре әрнегән менә шундый минутта бер кораллы солдат каяндыр килеп чыкты да: «Бу тирәдә йөрергә ярамый, рөхсәт ителми, сугыш җире бит бу!»— дип әйтә-әйтә, аларны окопларга таба ияртеп алып китте. Дөрес, сүгенмәде, җикеренмәде, әмма шулай да аларга җитә калды. Ана белән баланың куркуларыннан йөрәкләре, атылып чыгардай булып, еш-еш тибә башлады.

Өлкән лейтенант чакырылмаган кунакларның шундый рухи хәлдә икәнен сизеп алды да, урыныннан торып, аларны ачык йөз белән каршы алды. Кул биреп күреште, исәнләште, исемнәрен сорады. Хатын Анна исемле, ә малай Андрюша атлы икән.

Командир аларга урын тәкъдим итте, үзе дә яңадан нарат төбенә утырды.

Килүчеләр бу авыл кешеләре булып чыктылар. Авыл хәрабәсен карарга түгел, аны моңача берничә тапкыр күргәннәр, ә бәрәңге бакчасы нинди хәлдә икән дип белешергә килгәннәр икән. Орлыклык таба алсалар, бәрәңге утыртырга исәпләре бар: ничек тә яшәргә кирәк бит...

Ана әле һаман тынычлана алмый, каушый, борчыла иде. Шәйхуллин аның калтырана-калтырана сөйләгән сүзеннән бик аз нәрсә аңлады. Шулай да бер нәрсәне ачык төшенде: фашистлар бу авылны 1942 нче елның көзендә яндырганнар икән; авылны гына түгел, утыз сигез кешене, карт-корыны, хатын-кызларны, бала-чагаларны, амбарга куып кертеп, ут төртеп яндырганнар, алар арасында концлагерьдан качкан яралы бер кызылармеец та булган, фашистлар аңардан ни-

дер сорашканнар, нәрсәнедер белергә теләгәннәр, солдат бер сүз дә әйтмәгәч, аны бик каты кыйнаганнар, газаплаганнар; аннары кулларындагы утлы тимер белән башта аның аркасында, шуннан соң күкрәгенә биш почмаклы йолдыз ясаганнар да, аңын югалткач, үзен утка, әлеге утыз җиде кеше янына ыргытканнар... Өлкән лейтенант Шәйхуллин, утны-суны кичкән офицер, кайгылы, хәсрәтле ана авызыннан бу сүзләрне ишеткәч, күз яшьләрен көч-хәл белән тыеп торса да, тамагына ниндидер бер төер килеп тыгылды. Шуны таратыр өчен ул, постта басып торучы рядовой Николаевка таба борылып, үзенә дә бик сәер тоелган тавыш белән приказ бирде:

— Бар, кунакларны үз землянкагызга кертеп урнаштыр. Ерак җирдән килеп, бик арганнар. Ял итсеннәр. Старшина аларга аш китерер... Сибгатуллинга әйт: кунаклар янына берәүне дә кертмәсен. Аңладыңмы?

— Аңладым, иптәш командир!— диде дә Николаев кунакларны землянкага таба ияртеп алып китте. Тик шуннан соң гына өлкән лейтенантның тамагындагы төер таралган сыман булды.

...Бераздан, кырык-илле минуттан соң, рота командиры берничә солдат белән бергә землянкага барып кергәндә, кунаклар инде тынычланганнар, котелокларга салып китергән ашны да, бутканы да ашап бетереп, шикәрләп чәй эчеп утыралар иде. Алар, командир белән берничә солдатның килеп керүен күргәч, урыннарыннан тордылар да мондый зур сый-хөрмәт өчен бик зур рәхмәт әйттеләр. Ана башындагы шәле белән күз яшьләрен сөртеп алды.

Шәйхуллин кунакларга утырырга кушты. Утырдылар.

Командирның анага бер-ике соравы бар икән. Артык сораулар биреп йөдәтәсе килми иде аның, чөнки аларны бу тирәдән мөмкин чаклы тизрәк озатып җибәрергә кирәк иде. Көн кояшлы, җылы булса да, тынычсыз. Һавада фашистларның рамалары — разведка хезмәтен үтәүче самолетлары айкалып йөри башлады. Дошман артиллериясе икенче сафтагы окопларга берничә тапкыр аткалап алды.

Кунаклар белән кызыксынып, командирдан рөхсәт сорап, башка сугышчылар да килеп керде. Землянка ишеге шар ачылды, хәтта сугышчылар траншеяда да өелешеп басып торалар иде. Хатынның авызыннан чыккан сүзне барысының да ишетәсе килә.

Рота командиры, ананы исеме һәм әтисе исеме белән олылап:

— Ирегез кайда, Анна Павловна? Исәнме?— дип сүз башлап җибәрде.

Шөкер, исән икән.

— Немецлар илгә басып кергәннән соң ирем өйдә бер көн дә тормады,— диде хәсрәтле хатын.— Коммунист ул минем. Колхозда бригадир булып эшләде. Азык-төлек салган капчыгын аркасына асты да китеп барды. Минем урыным монда түгел хәзер, урманда, диде.

— Шуннан бирле күрешкәнегез юкмы?

— Бар, нигә булмасын. Беренче айларда еш очрашкаладык. Төннәрен, кешеләргә сиздермичә генә урманга, билгеләнгән урынга бара идем. Ипиен, тегесен-бусын дигәндәй илтә идем. Ашарларына кирәк ләбаса. Үзенә генә түгел, башкаларга да... Аннары килмәскә кушты. Дошман кешеләрнең күзәтүләре, сизүләре мөмкин, диде... Сизсәләр, кайгы-хәсрәтне җыеп бетерә алмассың, диде. Үзең беләсең, диде. Шуннан соң бармас булдым. Ярый әле ялгыз түгел. Авылдагы башка

ирләр дә аның белән бергә партизан булып киттеләр.

Сибгатуллин командир янындарак басып тора иде.

— Нихәл соң, үзеннән хат-хәбәр бармы болай?— дип сорады.

Хатынның җыерчыклы йөзе яктырып китте, күз карашы да нурланды:

— Сез бу тирәне азат иткәннән соң Мәскәү аркылы бер хат алдым үзеннән. Өстем-башым бөтен, тамагым тук, дигән. Һаман да партизанлыкта, дигән. Фашистларны тетәбез, утлы табага бастырабыз, дигән... Сез инде моннан тизрәк куыгыз ул мәлгуньне,— диде ул аннары сугышчыларга.— Дөньяда нәселләре калмасын!

Егетләр, дошманны тиз арада куачакларын белдереп, төрлесе төрле сүз әйтеп, бераз гөрләшеп алдылар.

Шәйхуллинның сорыйсы сүзләре бетмәгән икән әле.

— Коммунист хатыны булгач, теге җәһәннәмнән, уттан дип әйтүем, ничек котылып калдыгыз соң?— дип сорады Анна Павловнадан, уңайсызланып кына. Бу сүзләре белән ул хатынның әрнүле җиренә, йөрәк ярасына кагылуын сизә, белә иде.

— Әй,— дип кычкырып әйтеп куйды кунак хатын,— бу турыда сорашмасагыз яхшырак булыр иде! Яхшырак булыр иде!— Хатын башындагы шәлен чишеп алды да, шуның белән битен каплап, башын аска иде.— Аны күз алдына китерәсем килми. Белсәгез иде сез!.. Белсәгез иде!..

Землянка эче тынып калды. Алгы сафтагы атышларны исәпкә алмаганда, монда шылт иткән тавыш та юк иде. Тик җир шүрлектәге гильзалы лампа гына, тынычсызланып, борчылып, сөремләнеп яна, бер уңга, бер сулга талпынып, каядыр ашкына, омтыла.

— Шулай да?— диде Шәйхуллин, гаепле кеше сыман.

Хатын башын күтәрде. Аның чал чәче тузган, чәбәләнгән, күз яшьләре әле кибеп җитмәгән иде.

— Дөньяда ашыйсы ризыгым бетмәгән, күрәсең,— дип җавап бирде ул моңсу, хәсрәтле тавыш белән.— Ул коточкыч көнне мин, иртә белән иртүк торып, урманга, гөмбәгә дип киткән идем. Өй ишеген бикләп, ачкычын кесәмә тыктым. Андрюша белән Асеньканы да ияртгем. Кызым Андрюшадан ике яшькә кечерәк минем... Урамда очраган кешеләр әле әйттеләр үземә: Нигә бу хәтле таң тишегеннән кузгалдың? диделәр. Белмим, бернәрсә дә әйтә алмыйм, әллә күңелем сизенде, әллә инде дөньяда ашыйсы ризыгым бетмәгәнгә шулай туры килде...— Хатынның авызы кипкән иде. Җир сәке өстендәге кружканы кулына алып, бер йотым чәй эчте. Аннары ашыкмыйча гына, моңлы, хәсрәтле тавыш белән яңадан сөйләргә керешге:— Урманда гөмбә күп иде ул елны. Әллә кешеләр җыймаганга, әллә болай гына... Кызауларыбызны тутырганда кояш төшлеккә күтәрелгән иде инде. Кайтырга дип борылдык... Андрюшам алданрак бара иде. Урман авызына барып чыккач, йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде. «Әни, авылыбыз яна!» дип кычкырган икән ул. Ә мин бары «Яна!» дигән сүзен генә ишеттем. Нәрсә яна икән дип, урман кырыена йөгереп чыксам, әллә ни булды: башта кулымдагы кызау төшеп китте, аннары тез буыннарым мамык кебек йомшарды, күз алларым караңгыланды... Күпме ятканмындыр, белмим... Аңыма килгәндә, авыл тоташ ут эчендә иде... Янымда ике баламның икесе дә җылап утыра. Андрюшам әйтә: «Әни, тор, әйдә кайтыйк, ди. Өйдәге әйберләрне алып калыйк. Янып бетмәгәндер

әле», ди, ә Асенькам, мескенем, куллары белән итәгемә чатырдап ябышкан да: «Кайтмыйк, әни, ди. Куркам, ди. Немецлар килгәннәр анда, ди. Кешеләрне аталар, ди. Әнә чабышып йөриләр», ди. Калтырый, җылый. Ни әйтсәң дә, гөнаһсыз җан шул. Күңеле сизгән булса кирәк... Ә мин бернәрсә күрмим. Бары авылны чолгап алган утны гына... Әле ярый, кайтмадык. Ике атна чамасы урманда каңгырып йөрдек. Кырга чыгарга да курыктык. Бик ябыктык, ачыктык, атлар хәлебез калмады... Авылдан качып котылган кешеләрне дә очраттык. Ниләр булганын сораштык үзләреннән. Без авылдан гөмбәгә дип чыгып киткәч, бер сәгать чамасы вакыт узганнан соң килгәннәр икән ул ләгыйньнәр... фашистлар, ерткычлар... Башта авылны урап алганнар. Аннары ирләре яисә уллары партизан булып киткән семья членнарының барысын да... карткарчыкларны да, хатын-кызларны да, хәтта имчәк балаларын да амбарга яба башлаганнар...— Хәсрәте, әрнүе йөзенә чыккан ана сүзен әйтеп бетерә алмады, ничектер, сәер генә үксеп җибәрде дә, шәле белән битен каплап, яңадан башын түбән иде. Кешеләргә сиздермәскә, ишеттермәскә тырышып үкси идеме ул, әллә ыңгыраша гына идеме,— моны ачык әйтеп булмый иде.

Землянкадагы сугышчылар, утны-суны кичкән, үлемнең күзенә карап барган батыр егетләр, тыннарын да чыгармыйча, эндәшергә батырчылык итмичә басып торалар иде. Чөнки алар каршында хәсрәтеннән нишләргә белмичә тынып калган, изрәгән иске шәле белән битен каплаган ана иде, чынбарлык иде, хакыйкать иде.

Өлкән лейтенант Шәйхуллин, бу бәхетсез, хәсрәтле хатыннан башка берни дә сөйләтеп булмаслыгын төшенеп, җир сәке кырыена утырган җиреннән торды

да, сугышчан иптәшләренә карап, коры, ялкынлы тавыш белән кыска гына мөрәҗәгать итте:

— Иптәшләр, дусларым, ишетегез, белегез!— диде.— Менә бу авылда, бары йөрәк өзгеч хәрабәләре генә калган авылда, фашистлар, кан эчүче илбасарлар, утыз сигез кешене бер амбарга ябып, бензин сибеп, яндырып үтергәннәр. Араларында концлагерьдан качкан яралы бер кызылармеец та булган. Моның өчен фашистлардан үч алыгыз! Мәрхәмәтсез үч алыгыз! Моны беркайчан да онытмагыз! Әгәр сугыштан исән кайтасыз икән, бу дәһшәтле вакыйганы, канлы фаҗигане балаларыгызга сөйләгез! Оныкларыгызга да сөйләгез! Алар да белсеннәр, алар да онытмасыннар моны! Онытырга ярамый моны! Онытуы мөмкин түгел! Фашизмның ерткычлыгын, кабахәтлеген киләчәк буыннар да белсеннәр, алар да ишетсеннәр!...

Кайгылы ана шәле белән йөзен каплап бөгелеп утырган җиреннән әкрен генә, көч-хәл белән генә торды да солдатларга таба борылды. Сулуы кысыладыр, саф һавага чыгарга телидер дип уйлап, сугышчылар аңа ишеккә таба юл бирә башлаганнар иде, ләкин хатын баскан җиреннән кузгалмады. Үз-үзе белән сөйләшкәндәй, эчтән, йөрәгеннән чыккан саңгырау тавыш белән землянкадагы бөтен кеше ишетерлек итеп әйтте:

— Ә ике баланы, Наташа белән Юлия исемле ике нәни кызны, сәнәк белән кадап, коега ыргыттылар, диде.— Наташа алтыда, ә Юлия биштә генә иде әле. Алар куркып сыер абзарына, салам арасына кереп качканнар икән... Фашист дигән ике аяклы ерткычлар шуннан эзләп тапканнар аларны...

Землянкадагы сугышчылар, йөрәкләренең әрнүенә түзә алмыйча, бердәм ухылдап куйдылар.

Хатынның сүзе бетмәгән икән:

— Юлия шундый матур, шундый мөлаем йөзле нәни кыз иде. Сокланмаган кеше юк иде аңар...

Иртә белән биләмгә чыгып киткән мәче ул арада, ашарга вакыт җитте дип землянкага кайтып керде дә, өелешеп басып торган сугышчылар аяк арасыннан узып, тимер мич астына, үзенең калай табагы янына барып басты. Кунак малай, Андрюша, шунда, җир сәкедә, тимер мич янындарак, сугышчылар арасында кысылып утыра иде. Соры мәче, аны күреп алып, үз күзләренә ышанмыйча, башта аңа берничә минут бик гаҗәпләнеп карап торды. Аннары, чыннан да аның Андрюша икәнлегенә ышангач, әллә шатланып, әллә аны кызганып (анысы ничек булгандыр, белмим), әмма землянкадагы бөтен кешегә ишетерлек итеп, неп-нечкә тавышы белән бер-ике тапкыр мияулады. Андрюша, үз каршындагы соры мәчене күргәч, шундук, урыныннан сикереп торып, кычкырып җибәрде:

— Мурка!.. Әни безнең Мурка ич бу! Кара әле, исән икән!..

Ул арада инде мәче, җитез генә сикереп, баланың кочагына барып кергән иде. Бала аны иркәли, сөя, үбә, мәче дә иркәләнә, башы белән дә, бөтен гәүдәсе белән дә Андрюшага ышкына, аңа нидер әйтергә, нидер сөйләргә теләгәндәй, мырлый-мырлый, кечкенә генә кып-кызыл теле белән малайның кулларын да, битен дә, хәтта иренен дә ялаштыргалап ала иде.

Землянкадагы сугышчылар, моңа бик гаҗәпләнеп, шаулашырга керештеләр.

IV

Бер ярты сәгатьтән соң инде ефрейтор Әнәс Сибгатуллин, рота командирының приказы буенча, ана белән баланы олы юлга чаклы озатып, машинага утыртып

җибәрү өчен, аларны ияртеп хәрабәле авыл буйлап бара иде. Кулында автомат, иңендә бөрмәле капчык. Аңа дыңгычлап азык-төлек тутырылган. Моны саубуллашыр алдыннан кунак хатынга рота старшинасы китереп бирде. Сугышчылар да хәзинәләрендә булганнан өлеш чыгардылар. Аларын малай кулындагы капчыкка тутырдылар. Хәзер аны Анна Павловна, җилкәсенә салып, күтәреп кайта. Ә малай кулында соры мәче. Ул аны, Мурканы, куенына тыгып, иркәли-иркәли, нидер сөйләнә-сөйләнә, әнисе белән солдат абый артыннан калышмаска тырышып, ашыгып-ашыгып атлый, хәтта кай минутларда, артка кала башлагач, йөгергәләп тә куя. Андрюша көтмәгәндә, уйламаганда үзләренең мәчесен, Мурканы, очратуына, хәзер аны үзе белән бергә алып кайтуына бик куана. Шатлыгы бик зур аның бүген. Сугышчы абыйлар аларны ачык чырай белән каршы алдылар (орышып, куып җибәрерләр дип курка-курка гына килгәннәр иде), туйганчы ашаттылар, шикәрләп чәй эчерделәр, җитмәсә әле, ике капчык тутырып, ашау әйберләре дә биреп җибәрделәр. Тик менә Андрюша алардан кечкенә винтовка сорарга гына батырчылык итмәде. Сораса, аны да бирерләр иде, кызганмаслар иде. Ә винтовка ярап куяр иде. Дөнья шундый хәзер, винтовка кебек әйбернең бик кирәк чаклары була.

Урам уртасында ишелгән, җимерелгән, бары баганасы белән сиртмәсе калган бер кое бар иде. Алар шуның янынннан узып киттеләр.

Сибгатуллин кунак хатыннан:

— Шундамы? — дип сорады. «Фашистлар, теге ике кечкенә кызны сәнәк белән кадап, шунда ыргыттылармы?» — дип соравы иде аның.

Ана, үкереп елап җибәрүеннән куркып, бары башы белән генә ымлады. Бу аның «әйе, шунда» дигән

сүзе иде. Болай да аның бүген монда, туган авылының җирен кочып, бармаклары белән туфракны тырныйтырный, үксеп-үксеп елыйсы, йөрәгенә таш булып каткан кайгы-хәсрәтне эретәсе, таратасы килә иде. Бу хәсрәтнең, йөрәк өзгеч бу кайгының беркайчан да бетмәячәген, таралмаячагын, ә гомеренең соңгы минутына хәтле үзе белән бергә барачагын, онытылмаячагын белсә дә, туган-үскән җирне кочып еласам, йөрәгемдәге таш таралыр, эрер дип өметләнә иде ул.

Аннары ана белән бала үз йортларының нигезенә якынлаштылар, баруларыннан туктап, шунда бераз басып тордылар. Алар белән бергә Сибгатуллин да туктады, нигәдер, ул иңенә аскан автоматын кысыбрак тотты.

Бу нигез дә, авылдагы башка нигезләр шикелле, хәрабә хәлендә иде. Монда да чүп-чар, көл, күмер, янып бетмәгән бүрәнә калдыклары, кирпеч ватыклары, савыт-саба китекләре сибелеп ята. Акбуры яңгырлар, карбураннар белән юылган, ашалган мич җимерелеп бетмәгән икән. Ул ярым чалшаеп, гарипләнеп, бик моңсу, хәсрәтле булып, аларга таба корымлы авызы белән карап тора. Ул да, кайгысына түзә алмыйча, ыңгыраша, сыкрана шикелле...

Фашистлар, ике аяклы ерткычлар, бакчадагы алмагачларны да кисеп яндырганнар, аларны да юк итмәкче, корытмакчы булганнар, ләкин тормышның яшәү законы, аның мәңгелеге үзенекен иткән, алмагач төпләреннән үрентеләр шытып чыгып, күккә, кояшка таба сузылганнар.

Сибгатуллин хатынны бу урында тыела алмыйча, үкси-үкси елар дип куркып торган иде, әмма еламады, бары эчтән, бик тирәннән чыккан чамасыз хәсрәтле тавыш белән бер тапкыр сулкылдап алды да башында-

гы шәл чите белән күз яшьләрен ашыгып-ашыгып сөртте. Аннары ул үз-үзенә сөйләнгәндәй, әкрен генә, авыз эченнән генә әйтеп куйды:

— Бакчага бәрәңге утыртасы иде быел... Яшәргә кирәк бит... Болай булмый. Ни әйтсәң дә өч кашык күтәрәбез...

Аннары алар, авылдан чыгып, килгән якка — йокларга, ял итәргә дип түбән тәгәри башлаган кояшка таба карап киттеләр.

Жир дә, беленер-беленмәс кенә сузылып яткан юл да кибеп җитмәгән, пычрак иде әле, авыр туфрак аякларга сылана. Зур иске итек кигән Андрюша, пычрак ерып, чак атлап бара, әнисеннән дә, солдат абыйдан да калышмаска тырыша. Солдат абыйга рәхмәт, ул чаклы ашыгып атламый, алар җаена гына бара. Шәфкатьле, мәрхәмәтле кеше булса кирәк: «Аннушка, сиңа авырдыр. Бир әле капчыгыңны»,— дип әйтеп әнисе кулындагы капчыкны да үз җилкәсенә салды.

Алар һәркайсы, үз уена бирелеп, озак сөйләшми бардылар. Хатын гына, йөреш ритмын үзгәртеп, баруыннан туктап, туган авылына берничә тапкыр борылып карады.

Бераздан авыл, борылып карасаң да, күзгә күренмәс булды, ераклашты. Олы юлга — асфальт юлга да ерак калмады. Әле үзе күренмәсә дә, аннан йөк машиналарының узып-узып китүләре ишетелә башлады. Озакламыйча солдат ана белән баланы шул машиналарның берсенә утыртып җибәрәчәк. Барысын да белеп-ишетеп калырга теләгән ефрейтор Әнәс Сибгатуллин беренче булып сүз башлады:

— Авылыгыз янгач, урманнан кая киттегез? — дип сорады Анна Павловнадан.

Хатын тирән уйга чумып бара икән, Әнәснең сора-

вын ишетеп бетермичә, аңа беркадәр аптырап күтәрелеп карады:

— Нәрсә?.. Ни дисең?

— Авылыгыз янгач, урманнан кая киттегез, дип сорыйм. Авылыгызга кайттыгызмы?

Хатын, баруыннан кинәт туктап, ефрейторга гаҗәпләнеп карап алды да:

— Ой, ни сөйлисең син?! — дип кычкырып җибәрде.— Анда кайтырга ярый идемени соң! Авыл янып беткәч тә фашистларның бер өлеше шунда калган. Кайткан бер кешене атып үтергәннәр... Партизаннарның кайда икәнен беләселәре килгән.

Алар яңадан кузгалып киттеләр.

— Ике атна чамасы урманда ачыгып-каңгырып йөрдек,— дип, әкрен генә, моңлы гына итеп сүзен дәвам иттерде хатын.— Йөри торгач, дистәдән артык кеше җыелдык. Барысы да үзебезнең авылныкылар. Карт-карчыклар да, бала-чагалар да бар... Урманнан чыгарга курыктык. Һәркайда фашистлар, полицайлар... Бик ачыктык. Туңдык. Төннәр салкын булды ул чакта. Житмәсә, чыклы да иде. Бала-чагалар бик газап чиктеләр. Михась бабайга рәхмәт! Шундый бер карт бар иде арабызда. Житмешләр тирәсендә. Ул әйтте: «Болай ярамый,— диде.— Аулаграк җиргә барып урнашыйк, диде. Аннары күз күрер»,— диде. Безне урман эченәрәк ияртеп алып кереп, бер саз уртасындагы утрауга урнаштырды. Кеше күзенә чалынмаслык җиргә тәбәнәк кенә итеп шалаш корарштырдык. Астыбызга коры камыш белән коры үлән түшәдек. Өстебезгә ябынырга да шундый үсемлекләрдән үзебезчә нидер әмәлләдек.

Бик бирелеп тыңлап барган Әнәс Сибгатуллин, Анна Павловнаның сүзен бүлеп:

— Нәрсә ашап тордыгыз соң? — дип сорады.

— Әй, солдат, солдат,— диде аңа каршы Анна Пав-

ловна, хәсрәтле елмаеп,— кеше яшим дисә, яши ала икән. Бары өметсезлеккә генә бирелмәскә кирәк... Көз көне булганга, ашарга яраклы үсемлекләр корыган, кипкән иде. Авызга да алырлык түгел. Балтырган, кузгалакларны әйтәм, юа, сәрдә кебек әйберләрне. Әле ярый гөмбә бар иде. Чи хәлендә булса да ашадык. Миләшләр дә очраштыргалады. Мүк җиләкләре дә. Пешүен-пешмәгән иде әле алар. Шулай да ярап куйды. Кайбер үлән тамырларын да ашап була икән. Барысын да ашадык... Жан сакларга кирәк бит, ачтан үләсе килми... Шалаш әмәлләгәч, Михась бабай чакма ташлар табып алып кайтты. Шуларны бер-берсенә бәреп, ут чыгара алдык. Учак яга башладык. Ләкин барысын да бик куркып, яшеренеп кенә эшләдек... Шулай итеп, тормышыбыз бераз рәтләнеп киткән сыман булды. Гөмбәне утта кыздырып ашарга өйрәндек. Хәтта бер көнне Михась бабай, ерактагы кырга чыгып, чалбар балакларына тутырып, бәрәңге дә алып кайтты. Бик шәп булып куйды ул. Тик икенче бармады, кайда качып ятуыбызны дошманнар сизәр дип курыкты. Арабызда чая бер хатын бар иде. Ул да, төнлә ерак бер авылга барып, икмәк кисәкләре алып кайтты. Аңа бик шатландык. Ипи кисәкләрен тотып, исни-исни елаштык. Аларны балалар белән карчыкларга гына ашаттык. Ашау юклыктан, алар бик җәфа чиктеләр, бичаралар.

— Партизаннар очрамадымы соң?

— Очрады. Каңгырып йөрүебезгә ике атна тулып килә иде. Алар безне эзләгәннәр, ә без аларны.

— Иреңне очраттың алайса,— дип сүз кыстырып куйды Сибгатуллин.

Хатын сагышлы гына итеп башын чайкады:

— Очрата алмадым шул... Дядя Костя отрядында булган ул. Орша тирәсендә.

— Кем соң ул Дядя Костя?

— Белмисеңме әллә? Константин Заслонов* ул. Без аны Дядя Костя дип йөртәбез.

— Һай, аны белмиләрме соң! — дип, кычкырып әйтеп куйды Әнәс.— Аны да белмәгәч!.. Бик гайрәтле, батыр партизан булган ул мәрхүм. Һәлак булуын ишеткәч, бик кайгырдык.

— Без дә бик кайгырдык. Фашистларның котларын алып тора иде ул.

— Партизаннарны очраткач, аларга барып кушылдыгызмы?

Анна Павловна ефрейторга бераз көлемсерәп карап алды да:

— Ничек кушылыйк без аларга? — дип җавап кайтарды.— Бик кушылыр идек тә бит. Бала-чагалар, карчыклар белән нишләсеннәр алар? Шулай да Михась бабай белән әлеге чая хатын калды. Баласы юк иде аның. Партизаннарга болай да бик зур рәхмәт. Үзләрендә ике-өч көн тотып, ашатып-эчерттеләр дә, бераз хәл җыйгач, төрлебезне төрле авылга тараттылар. Мине сеңлем янына илтеп куйдылар... Малиновка авылына. Моннан кырык-илле чакрым ераклыкта ул. Барып кергәч, сеңлем танымады. Кочаклашып елаштык... Хәзер шунда торабыз... Землянкада... Аның да ике баласы бар. Ире армиядә, фронтта...

Тагын алар беркадәр вакыт сөйләшмичә бардылар. Инде асфальт юлдан гөжләп узучы машиналар тавышы көчлерәк ишетелә башлаган иде. Әнәс Сибгатуллин яңадан сүз башлады:

— Теге, яралы кызылармеецны әйтәм, сезнең авыл-

---

* Заслонов Константин Сергеевич (1910—1942) — Партизан чагындагы кушаматы — Дядя Костя. Бөек Ватан сугышы елларында Белоруссиядәге партизан хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, Советлар Союзы Герое.

га ничек килгән соң ул? — дип сорады. Ул, юан итеп төргән тәмәкесен тарта-тарта, әлеге солдат турында уйлап бара икән.

Хатын, бу сорауга җавап бирер алдыннан, нигәдер, шикләнеп, як-ягына карап алды. Аннары, әкрен генә, ашыкмыйча гына моңлы, хәсрәтле тавыш белән сөйләргә кереште:

— Фашистлар концлагереннан качкан ул. Үзе генә түгел, бер төркем иптәшләре белән. Шунда аягы яраланган. Артыннан атканнар... Берничә көн урманда качып яткан... Үзебезнекеләргә таба барырга тырышкан. Йә абаланып, йә таякка таянып, тыраклап, берничә көн көнчыгышка таба үрмәләгән... Ахырда, тәмам хәле беткәч, бер караңгы төнне ул, бик азапланып, шуышып, безнең авылга килеп җиткән дә, Михаил Митричның, безнең күршенең, бакчага караган тәрәзәсен әкрен генә шакыган. Митрич, моны ишетеп, бакчага чыкса, ни күрсен, җирдә яралы кеше ята. Хәлсез, кузгала да алмый, тиресе белән сөяге генә бар... Нишләргә? Ярдәмгә кешеләрне чакырыргамы әллә? Яралы кеше әйтә: «Пленнан качтым мин, ди. Зинһар, берәүгә дә әйтә күрмә», ди. Митрич бабай аны өенә күтәреп алып керә. Ашатаэчертә, ярасын юып бәйли. Аннары печәнлеккә яшерә. Кызылармеец аңа әйтә: «Аягым бераз төзәлү белән үк, партизаннарга китәм», ди. «Ят әле, ят, терел. Аннары китәрсең», ди аңа Митрич бабай. Бик шәфкатьле, мәрхәмәтле карт иде ул. Аны да яндырдылар. Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең! Ике улы Кызыл Армиядә иде, ә берсе, кечесе, ирем белән бергә партизан булып китте.

— Ул кызылармеецны үзең күрдеңме соң син?

— Күрдем. Ник күрмәскә? Авылда Митрич бабай белән икәү генә белә идек аны. Бер көнне Митрич бабай мине үзләренә чакырып алып керде дә сер итеп кенә

әйтте: «Анюта, ди, синең ярдәмең кирәк миңа, ди. Миндә яралы бер кызылармеец ята, ди. Икәүләп аякка бастырыйк аны, ди. Үземнең генә көчем җитми», ди. Риза булдым, билгеле. Нигә риза булмаска. Берәүгә дә әйтмәскә ант иттерде. Ант иттем.

— Кайсы якныкы иде ул?

— Казан ягыннан иде. Россиядә шундый бер шәһәр бар. Ишеткәнең бардыр, бәлки.

— Мин үзем дә шул яктан,— диде Сибгатуллин һәм бик кызыксынып сорады: — Исем-фамилиясе ничек иде?

Хатын да, кызыксынып, Әнәс Сибгатуллинга күтәрелеп карады.

— Беләдер идем дә, онытгым. Бик зур кайгы-хәсрәт кичердек бит. Кеше җаны күтәрә алмаслык... Аннары исеме дә, фамилиясе дә әйтергә читен иде. Безнеңчә түгел. Шулай да кайбер сөйләгән сүзләре хәтердә калган. Сугышка чаклы колхозда эшләгән. Хатыны, өч баласы булган...

— Нинди милләт кешесе икәнен әйтмәдеме?

— Әйтте. Анысын беләм. Татар дип атый иде ул үзен... Аягына басарлык булгач ук партизаннар янына китмәкче иде. Насыйп булмады мәрхүмгә.

— Әй, Аннушка, Аннушка, бик кызганыч, исем-фамилиясен оныткансың,— диде Сибгатуллин бик ачынып. Моны ул хатынга түгел, ә үз-үзенә зарланып, кайгырып әйткән шикелле итеп әйтте.— Онытмаган булсаң, хатынына хәбәр итәр идек. Кайда һәлак булганын белерләр иде. Ә хәзер алар аның кабере кайда икәнен дә белмиләр. Шунысы бик көенеч өйдәгеләргә. Бик көенеч! Тукта, менә нәрсәне әйт әле син миңа: немецлар аны эзләп килгәннәрме әллә?

Хатын, башын селкеп, кырт кисеп әйтте:

— Юк, аны эзләп килмәгәннәр. Ә партизан семья-

ларын үтерергә, яндырырга дип килгәннәр. Кызылармеец турында бер сүз дә әйтмәгәннәр хәтта сорашмаганнар да. Аның бездә качып ята икәнен белмәгәннәр алар.

— Алайса ничек тапканнар соң аны?

— Ничек тапканнар? Тапмаганнар. Үзе ул аларны, фашистларны дип әйтүем, печәнлектәге ярыктан күзәтеп яткан. Халыкны амбарга ябып, ишеккә, стеналарына бензин сибә башлагач, түзмәгән, немецлар янына үзе чыккан. Халыкны кызганган ул. Таякка таянып, бер аягы белән тыраклый-тыраклый чыкты, диләр. Аны эзлиләр дип уйлаган ул... «Сез эзли торган кеше менә мин ул! — дип кычкырган ул фашистларга.— Кешеләрне амбардан чыгарыгыз! Аларның гаебе юк!» дигән. Немецча да беразбелгән, ахры. Котылып калган кешеләр әйтәләр: немецча да кычкырды ул аларга, диләр.

Әнәс Сибгатуллин, баруыннан туктап, бераз башын чайкап торды да, әрнеп, уфтанып:

— Менә бит нинди геройларның исемнәре халыкка беленмичә кала,— диде.— Нинди кызганыч, нинди зур гаделсезлек! Хәтта туганнары да, балалары да белмиләр моны... Сугыш, сугыш! Ләгънәт сугыш!..

Яңадан кузгалып киткәч, Анна Павловна да:

— Бик батыр егет булган күрәсең ул,— дип сүзгә кушылды.— Ә карап торырга бер дә андый түгел шикелле иде үзе. Ябык, чандыр, буйга да зур түгел, минем хәтле генә... Өч атна чамасы ятты печәнлектә. Шул вакыт эчендә зарлануын, уфтануын бер тапкыр да ишетмәдем. Авыр көннәре аз булмады үзенең... Ул да миңа, синең кебек, Аннушка дип эндәшә иде... Без хәзер дә әле, аны искә төшереп, гаҗәпләнәбез. Халык өчен җанын кызганмады, дибез. Уйлап карасаң, без кем аңа? Туган да, тумача да түгел. Бөтенләй ят

кеше. Житмәсә икенче милләт кешеләре. Телебез дә башка. Бактың исә ул безне үзенең туганнарыннан да якын күргән. Үзем үлсәм үләм, әмма халыкны бу бәладән коткарам, дигән. Менә нинди батыр кеше булган ул. Ә карап торсаң бер дә андый кебек түгел шикелле иде.

— Йөрәктә ул батырлык, йөрәктә, ә беләктә түгел,— диде аңа каршы Әнәс Сибгатуллин.— Йөрәктә, жанда. Канда да... Син әйтәсең: башка милләт кешеләре без, дисең. Телебез дә башка, дисең. Телләребез башка булса да, жаннарыбыз бердәм безнең. Ватаныбыз да бер безнең. Беләсеңме, Аннушка, Ватан ул жаннан да кадерлерәк. Бөтен нәрсәдән кадерлерәк. Шуңа күрә бердәм сугышабыз да без. Бер ата балалары кебек.

— Беләбез, барысын да белеп, күреп торабыз. Бик шатланабыз моңа. Тик сез аларны, фашист ерткычларны, илебездән тизрәк себереп түгегез.

Сибгатуллин, рухланып, тавышын бераз күтәрә төшеп:

— Күп калмады, Аннушка, озакламыйча себереп түгәбез аларны,— дип кычкырып әйтеп куйды, һәм, уң кулын йодрыклап, янап та алды.— Сталинградтагы сугышлар турында ишеткәнең бардыр бит? Ә?

— Ишетмичә соң! Ишеттек. Ач-ялангач булсак та өч көн бәйрәм иттек. Жырладык та, жылаштык да... Шатлыгыбыздан жыладык.— Хатынның хәзер дә күңеле нечкәреп китте булса кирәк, шәл чите белән күз яшьләрен сөртеп алды.

— Аннушка, белеп тор, жанкисәгем, без әле ул кабахәтләргә тагын берничә Сталинградны күрсәтәчәкбез. Белеп тор моны! Авылдашларыңа да әйт. Алар да белсеннәр... Фашистларны илебездән себереп түгү белән генә чикләнмәбез, Берлинга да барып житәрбез.

Аны да алырбыз. Гитлерның да муенын борып ташларбыз. Моны да белеп тор, Аннушка., Шундый бәхетле көннәр дә булыр әле безнең... Бер заман сугыш та бетәр. Ирең дә исән-сау әйләнеп кайтыр. Үз авылыгызга бик матур итеп яңа йорт салып җибәрерсез... Гөр килеп яшәрсез...

Әнәс Сибгатуллинның бу сүзләрен ишеткәч, хатын, җиңеләеп, яшәреп киткәндәй:

— Ой, шундый матур сүзләрең өчен бик зур рәхмәт сиңа, солдат, бик зур рәхмәт! — диде.— Сүзләрең йөрәгемә май булып ятты, рәхәт булып китте. Андый бәхәтле көннәр тизрәк кенә килсен иде!

— Килер, килер, күп калмады инде.

Алар, сөйләшүләреннән туктап, һәркайсы үз уена бирелеп, бераз тын бардылар. Анна Павловна әле генә ефрейтор авызыннан ишеткән матур: күңелле сүзләр нәтиҗәсендә җылы хисләргә бирелеп барса, Әнәс Сибгатуллин күңелендә исә бөтенләй башка уй иде. Ул әлеге батыр егетнең исем-фамилиясен белә алмавы өчен борчыла, шуңа әрни. «Сугыш беткәч, барыбыз да туган-үскән өйләребезгә, хатыныбыз, бала-чагаларыбыз янына кайтырбыз,— дип уйлый ул.— Кызганычка каршы, миллионнар кайта алмаячак... Кайта алмаячак... Әлеге батыр егет тә кайтмаячак. Хатыны, балалары аның кайда, ничек һәм кайчан һәлак булуын белмәячәк. Туганнары да белмәячәк... Бик зур гаделсезлек бу, чамасыз зур гаделсезлек!..»

Әнәс Сибгатуллин шулай борчылып, әрнеп уйлап бара торгач, күңеленнән кинәт бер карарга килде дә баруыннан лып туктады:

— Кара әле, Аннушка, әгәр мин сиңа хатынымның адресын биреп калдырсам ничек булыр икән? — диде.

Анна Павловна аның сүзен аңлап бетермәде бул-

са кирәк. Баруыннан туктаган хәлдә аңа күтәрелеп карады:

— Нигә?.. Иреңне күр, ем дип язаргамы?

— Юк, аңа түгел, ә теге егетнең исем-фамилиясе исеңә төшсә дип әйтүем... Шуны хатыныма язып җибәрер идең. Дөрес, мин полевая почта адресын да бирә алам. Тик үзең беләсең, безнең адреслар әледән-әле алмашынып тора. Без йә монда, йә тегендә дигәндәй...

Хатын аның сүзен тиз аңлап алды:

— Язып калдырсаң, яхшы булыр. Дөнья хәлен белеп булмый. Кем белә, бәлки, исемә дә төшәр. Гомерем буе болай миңрәп йөрмәм.

Алар: юлдан читкәрәк кереп, корырак урынны сайладылар. Кыш буе кар астында ятып, соргылт төскә кергән калын үләнле җир иде бу. Кояш белән, язгы җилләр белән кибеп өлгергән иде инде.

Хатын белән малай бик арган икән,— килеп туктау белән үк җиргә утырдылар, малай исә сузылып ук ятты.

Мурка да, Андрюша култыгында ярым токтын хәлдә килеп, арган-талган булса кирәк,— малай җиргә сузылып яту белән үк аның култыгыннан чыкты да хуҗасы тирәсендә, мырлый-мырлый, ышкынып, иркәләнеп йөри башлады.

Әнәс тә, иңендәге капчыкларын салып җиргә куйгач, алар янына утырды. Окоплардан читтә, тыныч җирдә, офык итәкләренә таба тәгәрәп барган җылы кояш астында утыру рәхәт тә, күңелле дә иде аңа. Еракта, сугышлар барган җирдә, төштәге шикелле генә булып атыш тавышлары ишетелә, һавада, якында гына, баш очында, талпына-талпына бер тургай сайрый, үзенең моңын, сагышын, шатлыгын кемгәдер сөйли, кемгәдер җырлый.

Әнәс, сокланып, тургай тавышын бераз тыңлап торганнан соң, гимнастерка кесәсеннән кечкенә генә

бер кәгазь кисәге алды да аны автомат түтәсенә куеп, кулындагы бармак хәтле генә карандашы белән, бик тырышып, танырлык булсын дип, ашыкмыйча гына үзенең өй адресын язарга кереште. Язып бетергәннән соң адресы өстеннән күз йөртеп чыкты, тик шуннан соң гына Анна Павловна кулына сузды:

— Мә, югалтма, бик саклап тот. Әлеге егетнең исем-фамилиясе исеңә төшсә, шул адрес белән хәбәр итәрсең. Хатыныма мин үзем бу турыда тәфсилләп язармын.

Анна Павловна, кәгазь кисәген кулына алып, адреска күз ташлагач, нигәдер бер мәлгә тынып калды.

— Фатыйма... Хатыныгыз Фатыйма исемлемени? — дип сорады ул Әнәстән. Аннары, кашларын җыерып, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй авыз эченнән генә берничә мәртәбә кабатлады: — Фатыйма... Фатыйма...— һәм кинәт шатланып кычкырып җибәрде:— Әлеге егетнең исемен таптым, таптым! Фатих исемле иде ул! Фатих исемле иде! Шундый исем бармы сездә?

— Нигә булмасын, бар, бар! — диде Әнәс тә, чын күңеленнән куанып.— Чыннан да шулаймы, Аннушка?! Ялгышмыйсыңмы? Мондый эштә ялгышырга һич тә ярамый, Аннушка сеңлем.

Хатын, хәсрәтле зәңгәрсу күзләре белән Әнәскә туптуры карап, ышандырырлык итеп әйтте:

— Фатих исемле иде. Ялгышмыйм. Валлаһи менә! Шуңа күрә без аны Митрич бабай белән Федя дип йөртә идек. Тик фамилиясен генә хәтеремә китерә алмыйм... Болай булгач, анысы да исемә төшәр әле. Исемә төшү белән үк син биргән адрес белән язып җибәрермен.

Әнәс Сибгатуллин гимнастерка кесәсеннән тагын бер кәгазь кисәге чыгарды:

— Онытылмасын өчен моны язып куйыйк әле,— ди-

де ул, үз-үзенә сөйләнеп.—Онытырга ярамый моны. Һич тә ярамый! Шулай бит, Аннушка? — диде ул, Анна Павловнага җылы итеп карап. Хатын да, әлеге егетнең исемен хәтерли алуына чын күңеленнән шатланып, рухланып, аңа карап тора иде. Әнәс язуын дәвам иттерде: — Шөкер, шөкер, егетнең исемен беләбез хәзер... Казан тирәсендәге колхозларның берсеннән диган идең түгелме? Шулай бит, Аннушка? Анысын да язып куйыйк әле. Онытыла күрмәсен... Өч баласы бар икән дигән идең. Шулаймы? Хәтерләмисеңме, малайлармы, кызлармы икән алар? Бу турыда берәр сүз әйткәне булмадымы?

— Нигә булмасын, булды,— диде хатын.— Балаларын, хатынын исенә төшермәгән көне юк иде. Бик сагына иде ул аларны. Икесе кыз бала, берсе ир малай икәне дә хәтеремдә калган. Кече кызы сугыш башланыр көннәрдә генә туган. Аны да язып куй, солдат. Онытылмасын.

— Язабыз, язабыз, барысын да язабыз,— диде Әнәс Сибгатуллин.— Болай булгач, фамилиясен белмәсәк тә табабыз без аны. Тукта әле, тукта әле, Аннушка,— диде ул, хатынга туп-туры карап,— ничәдә иде ул? Белмисеңме?

Бәхеткә каршы белә икән.

— Утыз дүрттә иде ул. Берничә мәртәбә әйтте ул моны миңа.

— Болай булгач, безнең эшләр ал да гөл! — дип шатланып кычкырып әйтеп куйды Әнәс.— Сугыштан гына исән-сау кайтыйм. Аның гаиләсен үзем эзләп табам. Тапмыйча калмыйм. Батыр егетнең исемен, батырлыгын бөтен халык белергә тиеш. Батырларны онытырга ярамый, Аннушка җаным, онытырга ярамый! — Ахырда ул, Анна Павловнаның да адресын язып алып, ике кәгазьнең икесен дә партия билеты янчыгына

тыгып куйды.— Монда ул ышанычлырак сакланачак. Югалмаячак.— Шул сүзләрне әйтеп, ул уң кулының учы белән куен кесәсенә шапылдатып сугып та алды.

Аннары алар урыннарыннан кузгалып киттеләр һәм бераздан, каршыда яткан таллы-әрәмәле кечерәк бер сазлыкны урап узып, ниһаять, асфальт юлга барып чыктылар. Юл, гадәттәгечә, шаулый, гөрли, йөк машиналары уңга таба да, сулга таба да агылалар иде.

Машина көткән арада Сибгатуллин балага кайбер киңәшләр бирде:

— Син, Андрюша, мәчеңне кара, ашат. Кача күрмәсен,— диде.

— Качмый,— диде малай, кырт кисеп.— Минем яннан кая качсын ул?

— Мәсәлән, үзегезнең авылга. Элек торган җиренә... Мәченең гадәтен беләм мин. Шундый ул мәче...

Малай, үз-үзенә бик ышанып, фикерен тагын бер тапкыр кабатлады:

— Кая китсен ул! Минем мәче ич ул!

Сибгатуллин, Андрюшаның аркасыннан сыйпап:

— Алай булса, бик яхшы, бик яхшы,— дию белән генә чикләнде.

Анна Павловна нигәдер зарланып алды:

— Безнең ашатырлык әйберебез дә юк аңа. Сездә ул тук булган. Ашы, буткасы дигәндәй... Ите дә эләккәндер әле.

— Ашаттык, ашаттык, берсен дә кызганмадык,— диде ефрейтор.

Кызу гына узып барган бер буш йөк автомобилен кул күтәреп туктаткач, Сибгатуллин шофер белән сөйләште дә кунакларны машина кузовына уңайлап утыртты. Капчыкларны да алар янына куйды. Ана белән дә, малай белән дә кул биреп саубуллашты, ә Мурканың башыннан сыйпап: «Сау бул, пескәй!» — диде. Аннары Анна Павловнадан:

— Кара әле, Аннушка, авылыгызның исән калган кешеләреннән берәрсе теге татар егетенең исем-фамилиясен белмиме? — дип сорады.

Хатын бик үкенечле җавап бирде:

— Берәү дә белми шул аны. Митрич бабай белән икәү генә белә идек.

Машина кузгалып китәргә җыена иде инде. Шуңа күрә ефрейтор, бик ашыгып һәм кычкырып:

— Кара әле, Аннушка, кайда төшәсен беләсеңме? — дигән сорау бирде.

— Беләм, беләм! — дип тегесе дә кычкырып җавап кайтарды.— Төшкәч әллә ни ерак түгел. Бик тиз кайтып җитәрбез. Барыгызга да бик зур рәхмәт! Бигрәк тә командирыгызга!.. Шулай ук синең үзеңә дә бик зур рәхмәт! Яхшылыгыгызны онытмам!

Машина газ исе бөркеп, шаулап, гүләп китеп барды. Ефрейтор Сибгатуллин, юл кырыена баскан хәлдә, ераклашканнан-ераклаша барган кунакларга, сау булыгыз, дип кулын селкештергәләп торды да, алар тәмам күздән югалгач, күренмәс булгач, күпне күргән күн итеге белән зур-зур атлап, сугышлар барган җиргә таба юнәлде. Әлеге батыр егет турында кайбер мәгълүматлар туплый алуына, шуның өстенә соры мәченең дә хуҗалары табылып, аны үзләре белән алып китүләренә Әнәс Сибгатуллин җаны-тәне белән куанса да, күңеле нигәдер моңсу иде, аңа нидер җитми иде, бик кадерле бернәрсәне югалткан, аңардан мәңгегә аерылган сыман тоела иде аңа.

V

Ана белән малайны һәм мәчене машинага утыртып җибәргәннән соң бер атна узды, ике атна узды, ләкин Мурка үзенең туган-үскән җиренә кире әйләнеп кайт-

мады. Яңа җиргә ияләште булса кирәк. Дөресрәге, Андрюшадан аерылырга, аны ташлап китәргә теләмәде, ахры. Ефрейтор Әнәс Сибгатуллин моңа шатланды гына, килмәве яхшы. Ни әйтсәң дә, монда сугышлар бара, төрле хәл булуы мөмкин. Фашистлар, икенче сафтагы окопларны, дзотларны, ут нокталарын җимерергә, юк итәргә теләп, әледән-әле артиллерия налетлары ясап торалар. Кайчак бер төркем самолетлар да килгәләп чыга. Алар да тыныч кына узып китмиләр... Юк, монда кайтмавы, тынычта яшәве яхшырак Мурканың...

Соңгы вакытта полкка өстәмә көчләр килде, яңа кешеләр, яңа сугышчылар. Аларны роталарга, взводларга бүлеп тараттылар. Әхтәм Сафин отделениесенә дүрт кеше бирделәр. Отделение хәзер тулы канлы отделениегә әверелде. Землянка тыгызланды. Кайчак, бигрәк тә төнлә, аяк басарлык җир калмый.

Хәрби һөнәрне үзләштерү, дөресе, аны камилләштерү кызу темп белән бара. Сугышчыларга патроннарны да тиешенчә тутырып бирделәр, тик гранаталар гына өләшмәделәр әле. Хәер, алары да җитәрлек. Каты сугышлар булса, тагын бирерләр әле...

Кызу көннәр арасында мәче онытылды, бу турыда инде телгә алмый башладылар, тик ефрейтор Әнәс Сибгатуллин гына юксына иде аны. Ул хакта беркемгә әйтмәсә дә, күңеленнән чыкмый иде ул мәче. Чөнки бик ияләшкән иде ул аңа. Авылны, туган өйне, бала-чаганы ачыграк итеп күз алдына китерергә ярдәм итә иде ул.

Шулай бер көнне, караңгы төшкәч, снайпер Борис Михайловка аудан кайтып килгәндә, үз землянкаларыны җитәрәк, каяндыр мәче тавышы ишетелгән сыман булды. Ул, баруыннан туктап, бераз тыңлап торды: «Ялгыш ишетмимме икән?»

Аның ишетү сәләте, аучыларга хас, бик көчле иде. Ау вакытында ул урманда шылт иткән тавышны да

ишетә, кинәт туктап, бөтен көчен җыеп, тыңлап тора: кабатланмасмы? Монда, билгеле, беренче сафтагы атышлар комачаулый, тынычлап тыңларга ирек бирми, шулай да аучының түземлеге җитте, бик бирелеп тыңлый торгач, ниндидер бер мәченең елап, әрнеп кычкырган тавышы бу юлы ачыграк ишетелде. Снайпер җәнлекләрнең нинди хәлдә ничек кычкыруларын яхшы аера иде. Күрәсең, ниндидер бер мәче бәлага тап булган: елый, әрни, ярдәм сорап кычкыра.

Снайпер Борис Михайлов, траншеядан чыгып, караңгыда шул тавышка таба китте. Тавыш көчәйгәннән-көчәя бара. Димәк, мәче еракта түгел, ә бу тирәдә генә.

Баганасы гына исән калган әлеге коедан берничә адым читтәрәк, күгәргән, тутыккан чәнечкеле тимер чыбыклар тау шикелле булып өелеп ята иде. Ниндидер мәче шуңа кереп кысылган, шуннан чыга алмыйча азаплана икән. Снайпер, аны ачыграк күрер өчен, бигрәк тә аны сызландырмыйча, ансатрак коткарыр өчен, кулындагы фонаре белән яктыртып карады... Һәм акылыннан шашарлык дәрәҗәдә катып калды: соры мәче бит бу! Әлеге соры мәче! Мурка! Ничек кайткан ул монда? Үзенең туган-үскән авылын ничек тапкан?.. Аннары бу чәнечкеле тимер чыбык тавы эченә ничек барып кергән ул? Берәр тычканны яисә күсене тотам дип куып кергән булса кирәк. Их, син мәнсезне, мәнсезне!.. Үзең барып эләккәнсең бит капкынга, үзең... Ничек чыгарырга инде сине моннан? Ничек коткарырга? Михайлов, винтовкасын бер читкә куеп, мәчене коткарырга дип азапланып караса да, берүзе генә бу эшне башкара алмаячагын бик тиз төшенде.

Снайпер тимер чыбык тавы янында нишләргә белмичә бераз таптанып торды да, ярдәмгә берәр кешене алып килү өчен, зур-зур атлап, землянкага таба китте.

Землянкада рядовой Николаев кына иде.

Снайпер Михайлов, винтовкасын почмакка сөяп куйгач, соры мәченең нинди бәлагә очравын аңа берике сүз белән генә аңлатып бирде.

Алар тимер чыбык тавы янына ашыгып барып җиткәндә, мәче урыныннан кузгалмаган, баягыча һаман бик сыкранып мияулый, елый иде.

Егетләр, тимер чыбык тавын күсәкләр белән каергалап, Мурканы чак коткардылар. Снайпер аны кулына алу белән үк:

— Яраланган ич бу,— диде.— Аягы яраланган булса кирәк. Каный. Сырты да яраланган шикелле.

Алар аны кесә фонаре белән яктыртып карадылар.

Чыннан да, мәченең тәне берничә җирдән каты тырналган, канаган иде.

Снайпер аны, землянкага алып кермичә, туп-туры рота санинструкторы янына алып китте:

— Ярасын бәйләтергә кирәк,— диде.— Бәйләтмичә ярамый.

...Иртә белән, яктырып килгәндә, әле күмере сүнеп бетмәгән тимер мич янында Борис Михайлов белән Әнәс Сибгатуллин, дусларча тәмәке тартып, сөйләшеп утыралар иде, ә аяк астында, идәнгә җәелгән сырма өстендә Мурка ята. Сырты һәм арткы аягының берсе, уңы булса кирәк, марля белән уралган. Марля аша булса да ул аны әледән-әле ялаштыргалап ала. Бик ябыккан, сөяккә генә калган.

— Ярасы әллә ни түгел,— диде Михайлов, мәчегә караштыргалап.— Тырналган гына. Берничә җирдән. Шулай да каты тырналган. Тимер чыбык тавы арасыннан коткаргач та туп-туры санитар янына алып киттем үзен. Яраларын бик шәпләп бәйләттем. Озакламас, төзәлер... Санитар көлә, герой мәче, ди. Башкалар да көләләр... Чыннан да, акыллы икән Муркаң. Кеше акылы бар диярсең үзендә. Шулхәтле ерак җирдән кайткан бит. Ничек адашмаган? Юлны ничек тапкан? Гаҗәп, бик гаҗәп! Күрәсең, туган-үскән җир кешеләргә генә түгел, хайваннарга да кадерле, бик якын. Һай, туган-үскән җир шул ул, туган-үскән җир! Җырда тикмәгә генә сагынып җырламыйлар аны...

— Мәчеләр шулай алар,— диде Сибгатуллин.— Гадәтләрен беләм мин аларның. Кая гына китсәләр дә, яшәгән, күнеккән җирләренә әйләнеп кайталар. Ниндидер серле инстинкт, сизү хисе бар аларда. Мин барлык мәчеләрне дә бер чыбыктан кумыйм, ягъни барысында да шундый инстинкт бардыр дип уйламыйм. Әмма кайберләренең сәер гадәтләре турындагы хәбәрләр-

не ишетеп шаккатасың. Мәсәлән, сугышка кадәр ниндидер бер газетада язганнар иде. Мәскәү өлкәсендәге бер авылда яшәүче кешеләрнең туганнары аларның мәчесен Ленинградка алып киткәннәр икән. Күпмедер вакыттан соң әлеге мәче яңадан үз авылына, хуҗалары янына кире әйләнеп кайткан. Моны күреп, хуҗалары аптырап калганнар, ни әйтергә дә белмәгәннәр. Менә нинди алар, кайбер мәчеләр!..

Бу сүзләрне ишеткәч, Михайлов, бик гаҗәпләнеп, башын чайкап торды:

— Кара син аларны! — диде.— Моны син үзең укыдыңмы? Әллә берәр кешедән генә ишеттеңме?

— Үзем укыдым. Хәтта бу хәбәрне газетадан кисеп алып та куйган идем. Өйдә саклана торгандыр әле.

Михайлов, тәмәкесен тирән итеп суыргач, төтенен ашыкмыйча гына өреп, нечкә генә итеп чыгарды да:

— Өеңдәге мәче төсле икәнен ник әйтмәдең син аны миңа? — диде.

— Әйттем. Иптәшләр беләләр. Син генә ишетмәгәнсең.

— Шулайдыр, бик ихтимал. Мин бит сезнең янга йокларга гына кайтам,— диде снайпер. Бераз тынып торганнан соң, әкрен генә, ашыкмыйча гына сөйләргә кереште: — Сагышыңны аңлыйм мин, браток. Барыбыз да өебезне сагынабыз, беребез дә таш йөрәк түгел. Мин дә сагынам, тик әйтмим генә... Ике балам бар минем. Кечкенәләр әле...— дип, ул елмаеп куйды, балаларын күз алдына китерде булса кирәк. Моңача Сибгатуллинга кырыс, каты, ачулы булып тоелган бу кешенең йөзе кинәт матурланып, ягымлыланып китте, тавышы да сагышланды.— Мәктәпкә дә кермәгәннәр әле. Олысы Коля, кечкенәсе Настя исемле... Кайчак шундый сагынам үзләрен, шундый күрәсем килә! Чебен булып кайтып, тәрәзәдән карап торырга да риза. Күпкә

түгел, берничә минутка гына. Шул да җитәр кебек. Әйтергә оят, кайчак тамак төбе кытыкланып китә, үземне чак тыеп калам. Кешегә генә сиздермим. Йомшарып, җебеп китәрмен дип куркам. Ә йомшарсаң, ычкынып китсәң, сугыш авырлыгын күтәрүе ансат түгел. Шулай ул менә, браток. Ә син мине таш йөрәк дигән буласың. Юк, таш йөрәк түгел мин. Барыбызда да кешелекнең иң матур сыйфатлары бар. Дошманга гына кансыз, мәрхәмәтсез без. Дөресен әйткәндә, бу да бик матур сыйфат. Совет халкының бөек сыйфаты. Чөнки без, браток, илебезнең бәйсезлеге, азатлыгы өчен сугышабыз. Изге бурычыбызны үтибез. Канечкеч варварлардан дөньяны, цивилизацияне коткарып калырга телибез... Ә мондый сугышта дошманга каты бәгырьле, мәрхәмәтсез, шәфкатьсез булмыйча ярамый. Ярамый, браток, ярамый! — Аннары ул, сөйләвеннән туктап, тәмәкесен суыра-суыра, бераз уйланып торды да, нигәдер үкенгәндәй, моңсу бер тавыш белән әкрен генә сүзен дәвам иттерде: — Тагын шуны әйтәсем килә сиңа, браток. Сугышта йөри-йөри бик тупасландым мин. Кайчак иптәшләр белән бәхәсләшкәндә каты, тупас сүзләр әйтеп ташлыйм. Моның ярамый икәнен беләм, ләкин телемнән ычкынып китүен үзем дә сизми калам... Теге чакны әйтәм мин. Хәтерли торгансың... Кирәкмәгәнгә кычкырып салдым мин сиңа ул чакны. Мәчеңне атып үтерәм, дигән булдым, фәлән-фәсмәтән, дидем. Үтермәгән булыр идем мин аны. Болай гына, башым бик катканга гына ычкынып китте ул сүз. Мәче үтерү — снайпер эше түгел. Үтерсәм, бик зур хурлык булыр иде... Оныт син моны, браток, үпкәләмә. Ярыймы?

— Юк, үпкәләмим, Боря,— диде Сибгатуллин. Үпкә саклый торган егетләрдән түгел иде ул.

— Алайса, ярый. Озакламас, дошманны тәмам тар-мар итәрбез, сугыш бетәр. Хатыннарыбыз, бала-чага-

ларыбыз, туганнарыбыз янына, җиңүчеләр булып, бәхетле, саф күңелле кешеләр булып кайтырбыз. Бәгырьләребез йомшарыр. Ул көн ерак түгел, браток, түгел...

— Кичә Мурканы алып кайтуың өчен бик зур рәхмәт сиңа, Боря! — диде Сибгатуллин, аның сүзен бүлеп.— Баргансың, алып кайткансың. Ярасын да бәйләткәнсең... Өемдәге мәче төсле шул ул. Шуңа күрә яратам мин аны. Хәер, өйдәге төсле булмаса да яратыр идем. Мәче бит ул.

Бу минутларда Сибгатуллинга күңелле дә, рәхәт тә иде. Еракта, җиде тау, җиде урман артындагы авылны, бала-чагаларны, туган йортны искә төшерү, иптәшләрнең аңа булган җылы мөнәсәбәте, бу каты күңелле, кырыс холыклы булып тоелган снайперның, аны дус итеп, якын итеп, аның белән кара-каршы сөйләшеп утыруы бу беркатлы, яхшы ниятле, нечкә күңелле егетне тәэсирләндерә, дулкынландыра иде. Бу минутта аның күңеле иптәшләренә карата ихтирам белән, чиксез рәхмәт тойгысы белән тулы иде. Алар өчен ул, әгәр кирәк икән, электәгечә, җанын кызганмаска, утларга керергә, үлемнең күзенә карап барырга, аны җиңәргә, тетәргә әзер. Шундый яхшы хисләрдән булса кирәк, аның күңел кыллары тибрәнеп китте, дулкынлануын, хиска бирелүен снайперга сиздермәс өчен ул, сөйләвеннән туктап, бер читкә борылды да идәндә яткан коры чыраларның берсен алып тимер мич эченә ыргытты. Чыра шундук кабынып китте, күңелле генә чатнап, землянка эчен нурландырып, дөрләп яна башлады.

...Әнәс Сибгатуллин белән Борис Михайлов дусларча сөйләшеп утырган көннән соң бер атна чамасы вакыт узгач, караңгы, болытлы төннәрнең берсендә траншеяда постта торучы чуваш егете Василий Николаев землянка ишеген ачты да, йоклап ятучы иптәшләренең барысы да ишетерлек итеп:

— Подъем! — дип кычкырды. Аннары, сугышчыларның уянуын күргәч, әле генә, моннан берничә минут элек кенә взвод командирыннан алган приказны кабатлады: — Сугышка әзер хәлдә траншеяга чыгарга!

Беренче булып отделение командиры Сафин урыныннан сикереп торды, тиз арада киенеп бетереп, иптәшләрен ашыктыра башлады:

— Тизрәк! Кайсыгыз мыштырдый анда?! — Автоматын кулына алгач, землянкадан чыгарга команда бирде һәм үзе беренче булып траншеяга атылып чыкты.

Төн караңгы, ай да, йолдызлар да юк, бары алгы сафтагы окоплар тирәсендә ракеталар гына, зәңгәрсу нурларын сирпеп, һавага, кара болытларга таба күтәреләләр. Шуңамы, әллә башкагамы, баш очындагы болытлар тагын да карарак һәм авыррак булып тоелалар.

Сафин, отделениесен бер урынга туплагач, үзенең тәҗрибәсеннән чыгып, ачык бер фикергә килде: «Күчәбез икән. Тик кая күчәбез? Алгы сафкамы, әллә арткa, ялгамы?.. Ялга булса, шәп булыр иде. Отделениедә яңа кешеләр бар. Яшьләр. Аларның сугышчан осталыкларын камилләштерә төшәр идем... Әллә һөҗүм башланамы? Атакагамы?»

Взвод командиры тимер мич белән лампаны алырга кушкач: «Димәк, атакага түгел, яңа урынга икән»,— дип уйлап алды Сафин һәм шундук Сибгатуллин белән Николаевны землянкага җибәрде:

— Барыгыз, хәзер үк тимер мич белән лампаны алып килегез!

Борис Михайлов землянкадан чыгып өлгермәгән икән. Сибгатуллин килеп керү белән үк ул аңардан, дусларча шаяртып:

— Мурканы да әллә үзең белән алып китәсеңме? — дип сорады.

— Шаярма әле, зинһар,— диде аңа каршы Сиб-

гатуллин.— Болай да күңелем тыныч түгел. Ә син тагы җүләр сорау бирәсең. Нигә алып китим мин аны? Торган җирендә торсын. Авыл халкы бөтенләй кырылып бетмәгән. Исән калганнары да бар. Без дошманны куып киткәч, кайтырлар. Андрюша да кайтыр. Әнисе дә кайтыр. Мурканы күреп шатланырлар. Аларга да шатлык кирәк бит. Ни әйтсәң дә, бу мәче хәзергә бу авылда берданбер җан иясе... Берданбер җан иясе бит син, песекәй,— дип әйтә-әйтә, Мурканың башыннан соңгы тапкыр сыйпады да, шүрлектәге лампаны кулына алып, сүндереп, землянкадан йөгереп чыгып китте.

Аның белән бергә снайпер да чыкты.

— Ашарына салдыңмы? — дип сорады ул Сибгатуллиннан.

— Салдым. Буткам бар иде бераз.

Снайпер, противогаз сумкасыннан алып, аның кулына бер кисәк колбаса тоттырды:

— Мә әле, бусын да бир аңа.— Аннары, Сибгатуллин землянкага таба борылгач, аның исенә төшерде.— Ишекне ябып бетермә. Чыгып йөрерлек булсын.

Бераздан алар тагын икәү бергә киттеләр.

— Кара әле, браток,— диде снайпер иптәшенә.— Бик матур сүз әйттең бит син: «Аларга да шатлык кирәк», дидең. Барыбызга да кирәк шатлык, барабызга да!..

Отделение, тупланган җиреннән кузгалып, батальон сугышчылары белән бергә багланыш юлы буйлап алгы сафтагы окопларга таба тавыш-тынсыз гына бара иде инде. Әнәс Сибгатуллин, полкның кая таба һәм ни өчен бара икәнен төшенгәч, снайперга пышылдап кына эндәште:

— Боря, дускай, артык гранаталарың юкмы синең? Булса, бир әле, зинһар.

Борис Михайлов аңа ике граната сузды:

— Мә, миннән булсын яхшылык.

— Рәхмәт, дускай! Гранаталарым күп булганда тынычрак сугышам мин.— Аннары ул, снайпер белән саубуллашып, отделениесе артыннан йөгерде.

Күпмедер вакыт узар,— бер көнме, ике-өч көнме, хәер, анысын командование үзе белә,— дивизия, хәрәкәттәге армия белән берлектә, яңадан һөҗүмгә күчәр. Артиллерия әзерлеге тәмамланганнан соң, ефрейтор Әнәс Сибгатуллин беренчеләрнең берсе булып яисә беренче булып окоптан сикереп чыгар да, автоматын кысып тоткан хәлдә, полкташ иптәшләре белән бергә дошманга каршы атакага китәр, һәлак булган иптәшләре өчен дә, халкыбызның һәр тамчы каны өчен дә, яндырылган, хәрабә хәленә китерелгән авыллар, шәһәрләр өчен дә, хәтта азап чигеп йөргән бу соры мәче өчен дә — барысы өчен дә, барысы өчен дә дошманнан үч алыр, мәрхәмәтсез үч алыр.

15 тиен